СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.54, с. Верхний Услон,
422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы,
422570

РЕШЕНИЕ                                                  КАРАР

с. Верхний Услон

10.09.2018                                                  №44-209

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Уставын кабул итү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 44нче маддәсенә,”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 7нче маддәсенә туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советы**
**Карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Уставын №1 Кушымта буенча кабул итергә.

2. Әлеге карарны кануннар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәүенә җибәрергә.

3. Бу карар көченә кергән көннән көчен югалткан дип санарга:

- Югары Ослан җирле үзидарә Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставын кабул итү турында “, 30.06.2005нче ел, №8 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 12.09.2007нче ел, №17-95 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 09.09.2008нче ел, №27-147 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 13.12.2008нче ел, №31-170 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары

Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 15.05.2009нчы ел, №35-199 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 30.11.2009нчы ел, №40-225 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 08.06.2010нчы ел, №47-258 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 26.08.2010нче ел, №51-276 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 12.04.2012нче ел, №19-105 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 27.05.2013нче ел, №31-162 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 21.11.2014нче ел, №48-255 карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “, 13.03.2017нче ел, №22-103 карары;

4. Әлеге карарны кануннар белән билгеләнгән вакытта дәүләт теркәүеннән соң Татарстан Республикасы хокук мәгълуматы рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

**Совет рәисе,**
**ТР Югары Ослан**
**муниципаль районының**
**Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Зиатдинов**

Югары Ослан муниципаль районының
Югары Ослан авыл җирлеге Советының
10нчы сентябрь, 2018нче ел
№44-209 карарына

**Кушымта №1**

# Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Уставы

## Iнче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1нче маддә. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең исеме һәм хокук статусы

1. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге”муниципаль берәмлегенә авыл җирлеге статусы бирелгән.
2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме – “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге”(текст буенча алда- җирлек).
3. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы составына керә.

### 2нче маддә. Җирлекнең территориаль төзелеше

1. Җирлек территориясе составына түбәндәге торак пунктлар керә: Студенец авылы, Киров исемендәге посёлок.
2. Җирлекнең административ үзәге булып Югары Ослан саласы торак пункты тора.
3. Җирлекнең чикләре “Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территорияләренең чикләрен билгеләү һәм статусы һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр турында” 31.01.2005 ел, №19-ЗРТ Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән.
4. Җирлек территориясе составына җирләр милек һәм максатчан файдалану формасына карамастан керә.
5. Җирлекнең чикләрен үзгәртү, аларны үзгәртеп кору кануннар билгеләгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Кануны тарафыннан тормышка ашырыла.

**3нче маддә. Гражданнарның җирлектә җирле үзидарәне тормышка ашыруга хокукы**

1. Җирлектә җирле үзидарәне тормышка ашыру аның халкы тарафыннан җирле референдумда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы һәм туры теләк белдерүнең башка формалары белән, шулай ук әлеге Устав белән каралган җирле үзидарәнең сайлау һәм башка органнары аша тормышка ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне тормышка ашыруда җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәт һәм дәүләт хезмәтендәге хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, иҗтимагый оешмаларда булуына карамастан, бәйсез рәвештә дә, үзләренең вәкилләре аша да тигез хокукка ия.

Җирлек территориясендә даими яки күбесенчә яшәгән чит ил гражданнары җирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе халыкара килешүе һәм федераль кануннар белән туры китергән хокукларга ия.

3. Һәр кеше турыдан-туры җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хезмәтендәге затларга мөрәҗәгать итергә, җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында мәгълумат алырга хаклы.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге затлары һәркемгә турыдан-туры аның хокуклары һәм ирегенә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга мөмкинлек бирергә бурычлы, шулай ук гражданнарга, канун белән башка нәрсә каралмаган булса, Җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм ышанычлы мәгълуматларны алырга мөмкинлек бирергә тиеш.

5. Җирлекнең җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълумат чаралары аша һәм башка юл белән халыкны Җирлек һәм аның аерым территорияләре үсешенең иң мөһим мәсьәләләре турында, гомуми кулланышта булган транспорт, торак-коммуналь хуҗалыгы, халыкка хезмәт күрсәтүче иҗтимагый-мәдәни һәм башка оешмаларның эшчәнлеге һәм хезмәт челтәре үсеше турында, иҗтимагый өстенлекләр турында, җәмәгать тәртибен саклау торышы турында һәм табигатьтәге һәм техноген характердагы гадәттән тыш чаралар турында даими хәбәр итеп тора.

6. Гражданнар, оешмалар хокуклары һәм иреге бозылса, җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт хезмәтендәге затларның карарлары, гамәлләре (гамьсезлекләре) өчен судка шикаять бирергә хокуклы.

**4нче маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының төзелеше**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының төзелешенә, әлеге Уставка туры китереп барлыкка килгән, җирлек Советы, җирлек Башлыгы, җирлек Башкарма комитеты, җирлекнең Ревизия комиссиясе, җирле үзидарәнең башка органнары керә.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының төзелешенә үзгәрешләр әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән тормышка ашырыла.

**5нче маддә. Җирлекнең аерым бер урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләре**

1. Җирлек кармагында булган җирлекнең аерым бер урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлекнең бюджеты проектын төзү һәм карап чыгу, җирлекнең бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тотуны тормышка ашыру, җирлекнең бюджеты үтәлеше турында отчётны төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салым һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) җирлекнең муниципаль милегендә булган мөлкәткә ия булу, аны куллану һәм аннан файдалану;

4) җирлекнең чикләрендәге торак пунктларда янгын чыгу куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

5) җирлек составына кергән җирлекләрдә элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә шартлар тудыру;

6) җирлек составына кергән җирлекләрдә ял һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә шартлар тудыру;

7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерүгә шартлар булдыру, муниципаль районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру;

8) җирлекнең архив фондын формалаштыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тотуны тормышка ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләргә туры китереп җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

10) адреслау объектларына адреслар бирү, адресларны юк итү, үзгәртү, урам-юл челтәрләре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларыннан кала, региональ автомобиль юллары яки муниципаль җирлек ара әһәмияткә ия булган юллардан кала ), муниципаль районның авылара территорияләре чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәрен бирү, шул исемнәрне үзгәртү, юк итү, дәүләт адреслар реестрында мәгълуматны урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы производствасын үстерүгә булышу, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм тормышка ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның оешмаларына ярдәм итү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), ташу буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;

15) күмү урыннарын карап тору, ритуаль хезмәтләрне оештыру;

16) җирлек чикләрендәге торак пунктларда халыкны су белән тәэмин итүне, Россия Федерациясе кануны билгеләгән вәкаләтләре кысаларында халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урын өчен әһәмиятле булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телен һәм мәдәниятен үстерүгә ярдәм итү, милләтләр арасында килешүне ныгытуга юнәлтелгән чараларны булдыру һәм тормышка ашыру, күчеп килгән халыкларның иҗтимагый һәм культуралы җайлашуын, милләтара (этникара) низахларны булдырмый калуны тәэмин итү;

19) җирлек халкына массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру, җирлек халкының массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, гомуми

кулланышта булган су объектларына һәм аларның яр буена гражданнарның ирекле керүен тәэмин итү.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Югары Ослан муниципль районы составына кергән аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән яраклаштырып, муниципаль район бюджетыннан шушы җирлекләр бюджетына бирелгән бюджетара трансфертлар хисабына, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында килешү төзергә хокуклы.

Муниципаль районның җирле үзидарә органнары җирлекнең җирле үзидарә органнары белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән яраклаштырып, муниципаль район бюджетыннан җирлек бюджетына бирелгән бюджетара трансфертлар хисабына, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында килешү төзергә хокуклы.

### 6нчы маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының җирлекнең аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләргә карамаган мәсьәләләрен чишүгә хокуклары

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирлек музейларын төзүгә;

2) җирлектә нотариус булмаган очракта, канунда каралган нотариаль эшчәнлек башкаруга;

3) опека һәм тәрбиячелек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнашуга;

4) җирлек территориясендәге җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле булган эшчәнлекне тормышка ашыруда шартлар булдыруга;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм Җирлек территориясендә милләтара бәйләнешләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга булышлык итүгә;

6) җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең мобильләшкән әзерлек буенча чараларны оештыруда һәм тормышка ашыруда катнашуга;

7) муниципаль янгын сүндерү сагын булдыруга;

8) туризмны үстерүгә шартлар булдыруга;

9) кеше хокукларын яклаучы иҗтимагый контрольне тормышка ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтергә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга булышлык итүгә;

10) инвалидларның иҗтимагый оешмаларына ярдәм күрсәтергә, шулай ук “Россия Федерациясендә инвалидларны иҗтимагый яклау турында” 24нче ноябрь, 1995нче ел, №181-ФЗ Федераль канунына яраклаштырып бөтенроссия иҗтимагый инвалидлар оешмалары төзегән организацияләргә ярдәм итүгә;

11) торак турында канун белән туры китереп гражданнарга муниципаль торак фонды торак йортларын социаль кулланудагы торак фонды торак йортларын найм килешүе буенча бирүгә;

12) җирлек территориясендә яшәгән караусыз хайваннарны тотып алу һәм асрау буенча чараларны тормышка ашыруга;

13) “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында ” 23нче июнь, 2016нчы ел, №182-ФЗ Федераль канунында каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга;

14) инвалидларның, сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикле булган кешеләр өчен физик культура һәм спортны, җиңелләшкән спортны һәм җиңелләшкән физик культураны үстерүгә булышлык итүгә;

15) “Кулланучыларның хокукларын яклау турында” 7нче февраль, 1992нче ел, №2300-1 Россия Федерациясе Канунында каралган кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашыруга.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары әлеге маддәнең 1нче өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне, әгәр бу катнашу федераль кануннар белән каралган булса, башка дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруда катнашырга хокуклы (“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунына туры китереп аларга тапшырылмаган булса), шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең, дәүләт власте органнарының җирле үзидарә органнары компетенциясенә карамаган һәм федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән аларның компетенциясеннән алып ташланмаган башка сорауларны чишәргә хаклы, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән, бюджетара трансфертлардан кала, җирлек бюджеты кереме хисабына гына, һәм өстәмә норматив аерым бирелгән сумма буенча салым кереме хисабына чишәргә хаклы.

**7нче маддә. Җирлекнең муниципаль ара хезмәттәшлектә катнашуы**

Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы федераль канун һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә турында кануны белән туры китереп тормышка ашырыла.

**8нче маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән үзара бәйләнеше**

Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән үзара бәйләнеше түбәндәгеләр аркылы тормышка ашырыла:

1) Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Җирлекнең иҗтимагый-икътисад үсешенә юнәлтелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;

2) Җирлекнең җирле үзидарә органнары белән дәүләт власте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яки вакытлы координацион, консультатив, киңәшләшүче башка эшче органнар төзү;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Җирлек Советының законнар чыгаруга хокук инициативасы;

5) кануннарда билгеләнгән башка үзара бәйләнеш формалары.

**9нчы маддә. Муниципаль хезмәт хокукын җайга салу**

Җирлектә муниципаль хезмәт хокукын җайга салу, муниципаль хезмәт вазифаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәрнең статусын билгеләүне, муниципаль хезмәтне үтү шартларын һәм тәртибен кертеп, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2нче март, 2007нче ел, №25-

ФЗ Федераль кануны, муниципаль хезмәт турында 25нче июнь, 2013нче ел, №50-ЗРТ Татарстан Республикасы Кодексы һәм җирлекнең муниципаль хокук актлары белән тормышка ашырыла.

## IIнче бүлек. Халык тарафыннан турыдан–туры җирле үзидарәне тормышка ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу формалары

### 10нчы маддә. Халыкның турыдан–туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуы

Җирлек халкы турыдан–туры җирле үзидарәне тормышка ашыра һәм җирле үзидарәне тормышка ашыруда түбәндәге формаларда катнаша:

1) җирле референдум;
2) муниципаль сайлаулар;
3) җирле үзидарә сайлаган дәүләт хезмәтендәге зат, җирле үзидарә сайлау органы вәкиле, депутат чакыруы буенча тавыш бирү;
4) район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;
5) гражданнар җыены;
6) гражданнарның иҗади хокук инициативасы;
7) иҗтимагый территориаль үзидарә;
8) авыл җирлеге старостасы;
9) халык алдында тыңлаулар, җәмәгатьчелек тикшерүе ;
10) гражданнар җыелышы;
11) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);
12) гражданнарны сораштыру;
13) җирле үзидарә органнарына халыкның мөрәҗәгате;
14) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы кануннарына каршы килми торган башка формалар.

Җирлекнең җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятие, учреждение һәм оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, канун белән башка нәрсә каралмаган булса, килешү нигезендә төзелә.

### 11нче маддә. Җирле рефререндум

1. Җирле референдум, федераль кануннарга һәм Татарстан Республикасы кануннарына туры китереп, әһәмиятле булган мәсьәләләрне турыдан-туры Җирлек халкы тарафыннан хәл итү максатыннан уздырыла.

2. Җирле референдум Җирлекнең барлык территориясендә уздырыла.

3. Җирле референдумда яшәү урыннары җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнаша. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм туры теләк белдерү нигезендә яшерен тавыш бирүдә катнаша.

4. Җирле референдумны уздыру турында карар Җирлек Советы тарафыннан түбәндәге инициативалар буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукы булган гражданнар;
2) сайлау оешмасы, уставларында сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашу каралган һәм федераль кануннар билгеләгән тәртиптә һәм срокта теркәлгән башка иҗтимагый оешма;

3) бергә тәкъдим ителгән, Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе.

5. Җирле референдумны билгеләүгә шартлар булып гражданнар, сайлау оешмалары, башка иҗтимагый оешмалар инициативасы буенча әлеге инициативаны хуплап, федераль кануннарга туры китереп, Җирлек территориясендә теркәлгән, референдумда катнашучыларның 5 проценттан күбрәк булмаган санда җыелган имзалар тора.

6. Җирле референдумны уздыру турында Җирлек Советы белән Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе берлектә тәкъдим иткән инициатива Җирлек Советы карары һәм Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән теркәлә.

7. Җирлек Советы җирле референдумны, Җирлек Советына алар нигезендә җирле рефрендум билгеләнгән документлар килгән көннән 30 көн эчендә билгели.

8. Җирле референдумда тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

9. Җирле референдумда кабул ителгән карар Җирлек территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш һәм башка дәүләт власте органнары, аларның дәүләт хезмәтендәге затлары яки Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан расланырга тиеш түгел.

10. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен, әлеге Уставта билгеләнгән алар арасындагы вәкаләтләр бүленешенә туры китереп, тәэмин итә.

11. Җирле референдумны уздыру турында һәм җирле референдумда кабул ителгән карар, федераль кануннарга туры китереп суд тәртибендә шикаять бирелә ала .

12. Җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына төп гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында" Федераль канун белән һәм "Җирле референдум турында" Татарстан Республикасы Кануны белән җайга салына.

**12нче маддә. Муниципаль сайлаулар**

1. Җирлектә муниципаль сайлаулар җирлек Советы депутатларын, җирле үзидарә сайлау органнары вәкилләрен сайлау максатында яшерен тавыш бирү юлы белән гомуми тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә үткәрелә.

Муниципаль сайлаулар җирлек Советы тарафыннан "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына төп гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында" 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль кануны белән каралган вакытка билгеләнә. Федераль канун белән билгеләнгән очракта муниципаль сайлаулар җирлекнең сайлау комиссиясе яки суд тарафыннан билгеләнә.

2. Җирлек Советы депутатын сайлаулар үткәрү өчен "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына төп гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында" Федераль кануны таләпләре белән туры китереп бермандатлы һәм (яки) күпмандатлы сайлау округлары оеша.

Җирлек Советы депутатын сайлаулар гамәлдәге канун белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта үткәрелә һәм мәҗбүри, кабатланып була.

3. Җирлек Советы депутаты булып сайлау көненә 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданины сайлана ала, җирле үзидарәнең сайлау органы

әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесе булып сайлау көненә 21 яше тулган гражданин була ала.

Россия Федерациясенең халыкара килешүләре нигезендә һәм канун белән билгеләнгән тәртиптә җирлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарә органнарына сайларга һәм сайланырга хокуклары бар, Россия Федерациясе гражданнары кебек үк шундый ук шартларда башка күрсәтелгән сайлауларда катнаша алалар.

4. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесләрен сайлауларны әзерләү һәм уздыру гамәлдәге канун белән туры китереп сайлау комиссияләре тарафыннан тормышка ашырыла.

5. Тавыш бирүдә катнашучы сайлаучыларның күпчелек тавышын җыйган кандидат сайланган булып исәпләнә. Әгәр тавыш бирү бер кандидатура буенча үткәрелгән булса, тавыш бирүдә катнашучы сайлаучыларның 50 процент тавышын җыйган кандидат сайланган булып исәпләнә. Теркәлгән кандидатлар тигез тавыш җыйган очракта, алдан теркәлгән кандидат сайланган булып исәпләнә.

6. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайлау нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Җирлек Советы депутатларын сайлау нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе, кандидатлар исемлекләре арасында һәм кандидатларның исемлеге эчендә депутат мандатларын бүлү, сайланган җирлек Советы депутатларын һәм җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесләрен теркәү һәм Җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен сайлау нәтиҗәләрен билгеләү гамәлдәге канун белән билгеләнә.

**13нче маддә. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирү.**

1. Җирлек Советы депутаты, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесе, шул исәптән җирлек Башлыгы, гамәлдәге канун һәм бу Устав белән билгеләнгән сәбәп буенча һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан чакыртып алына алалар.

2. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алуга нигез булып суд тәртибендә расланган депутатның, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесенең аңа карата сайлаучыларның ышанычын шик астына куйган һәм депутат вазифаларын яки җирлек Советы Башлыгы вазифаларын башкармауында чагылган хокукка каршы конкрет карарлары яки гамәлләре (гамьсезлекләре), депутат статусы, җирлек Башлыгы белән туры килми торган гамәлләр эшләү, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив хокук актлары, бу Устав һәм башка муниципаль хокук актларын бозу тора.

3. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча үткәрелә.

4. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтү өчен һәм аны яклап гражданнар имзаларын җыю өчен, муниципаль

сайлауларда катнашу хокукы булган 10 кешедән дә ким булмаган инициатив төркем оеша.

5. Инициатив төркем җирлекнең сайлау комиссиясенә инициатив төркемне теркәү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Инициатив төркемнең үтенечендә депутатны, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алуга нигез булган хокукка каршы конкрет карарлары яки гамәлләренә (гамьсезлекләре) күрсәтмә булырга тиеш, инициатив төркемдәге һәр кешенең һәм җирлек территориясендә аның исеменнән вәкил булып эш иткән шәхесләрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне һәм урыны, аны биргән органның исемен яки кодын күрсәтеп, паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, шулай ук инициатив төркемдәге һәр кешенең һәм җирлек территориясендә аның исеменнән вәкил булып эш иткән шәхесләрнең тору урыны адресы күрсәтелә. Инициатив төркемнең үтенеченә күрсәтелгән төркемнең һәрбер әгъзасы кул куярга тиеш. Үтенечкә хокукка каршы конкрет карарлары яки гамәлләре (гамьсезлекләре) расланган суд карары беркетелә.

6. Инициатив төркемне теркәү, Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрү инициативасына булышлык итү өчен имзалар җыю, җыелган имзаларны тикшерү җирле референдумны үткәрү өчен Канун белән билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

7. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү җирлек Советы тарафыннан билгеләнә һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль кануны белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып җирле рефререндумны үткәрү өчен канун белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Аңа карата чакыртып алу инициативасы күрсәтелгән депутат, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесе җирлек Советы утырышында катнашырга хаклы, аның депутатларына чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрүгә каршы булуын язмача бирергә хаклы, шулай ук телдән чыгышында чакыртып алу өчен нигез сыйфатында күрсәтелгән шартлар буенча аңлатма бирергә хаклы. Күрсәтелгән депутат, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесенә җирлек Советы утырышы турында аны үткәргәнче өч көн алдан хәбәр ителә.

8. Депутатны, җирле үзидарәнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрүне билгеләү турында карар аны кабул иткәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

9. Җирлек Советы депутаты, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесе аларны чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү вакытында чакыртып алуга нигез сыйфатында күрсәтелгән шартлар буенча аңлатма бирү максатыннан инициатив төркем белән тигез нигездә агитация алып бару хокукына ия.

10. Җирлек Советы депутаты, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесе, шул исәптән җирлек Башлыгы, чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, чакыртып алынган дип санала.

11. Җирлек Советы депутатын, җирлекнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесен чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

12. Җирлекнең сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләренә рәсми рәвештә йомгак ясалганнан соң 5 көн эчендә инициатив төркемгә, җирлек Советына һәм җирлек Советының тиешле депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган хезмәттәге шәхесенә аны чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында язмача рәвештә хәбәр итә.

**14нче маддә. Җирлекнең чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп коруга халыкның ризалыгын алу максатыннан уздырыла.

2. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү бөтен җирлек территориясендә уздырыла, яки аның территориясенең аерым өлешләрендә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль кануны билгеләгән очракта уздырыла.

3. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү җирлек Советы тарафыннан һәм федераль кануннар һәм “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Кануны билгеләгән тәртиптә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль кانунында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнә.

4. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, анда сайлау хокукы булган җирлек халкының яртысыннан артыгы яки җирлекнең бер өлеше катнашса, булган дип санала. Күрсәтелгән үзгәртү һәм үзгәртеп корулар өчен тавыш бирәдә катнашкан җирлек халкының яртысыннан артыгы яки җирлекнең бер өлешенең яртысыннан артыгы тавыш бирсә, җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп коруга халыкның ризалыгы алынган дип санала.

5. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

**15нче маддә. Гражданнарның турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасы**

1. Җирлек халкы әлеге Устав һәм Җирлек Советы норматив хокук актлары билгеләгән тәртиптә турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасы хокукына ия.

2. Турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасы белән сайлау хокукы булган Җирлек халкының 3 проценттан ким булмаган актив сайлау хокукы булган гражданнар төркеме чыга ала.

3. Турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыру максатларында Җирлек халкы хаклы:

турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тикшерү һәм күрсәтү буенча халыкның яшәү һәм эш урыннары буенча гражданнар җыелышлары һәм башка коллектив чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын күрсәтүгә ярдәм итү өчен имзалар җыю буенча инициатив төркемнәр оештыру;

турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын күрсәтүгә ярдәм итү өчен Җирлек халкыннан имзалар җыю һәм агитация алып баруны кануннарга каршы килми торган юллар белән үткәрү.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге затлар һәм органнар Җирлек халкына турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыруда булышлык итәргә тиеш.

5. Гражданнарның турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проекты, әлеге Устав белән билгеләнгән үзләренең компетенцияләре кысаларында җирлек Башлыгы яки Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан Җирлек Советының ачык утырышында аны керткәннән соң өч ай эчендә каралырга тиеш.

6. Гражданнарның турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын караган вакытта гражданнарның инициатив төркем вәкилләренә үзләренең позицияләрен күрсәтеп бирергә мөмкинчелек булдырылырга тиеш.

7. Гражданнарның турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын карап чыгу процедурасы Җирлек Советы Регламентына, Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитетының норматив хокук актларына туры китереп билгеләнә.

8. Гражданнарның турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын карап чыгу нәтиҗәләре буенча кабул ителгән мотивлаштырылган карары рәсми рәвештә язма формада аны керткән гражданнар төркеменә җиткерелергә тиеш.

**16нчы маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә**

1. Җирлектә территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан гражданнарның җыелышлары һәм конференцияләр уздыру юлы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары оештыру белән тормышка ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яшәгән түбәндәге территорияләр кысаларында тормышка ашырыла: күпфатирлы торак йортлар подъездында; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булмаган торак пункт; гражданнар яшәгән башка территорияләрдә .

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылган территория чикләре элеге җирлекнең территориясендә яшәгән халык тәкъдиме буенча җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылган территория башка охшаш территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә аның уставы кысаларында юридик зат була ала һәм коммерцияле булмаган оешманың оештыру-хокук формасында дәүләт теркәүен узарга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнә:

1) ул тормышка ашырылган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максаты, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының формалашу тәртибе, вәкаләтләре туктатылу, хокуклары һәм бурычлары, органнарының вәкаләтлек вакыты;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук әлеге мөлкәтне һәм финанс чараларын куллану һәм эш алып бару тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең туктатылу тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, конференцияләр аның уставына туры китереп чакырыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, өчтән бер өлешеннән ким булмаган уналты яше тулган аның территориясе халкы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның конференцияләре гражданнар җыелышында өчтән бер өлешеннән ким булмаган уналты яше тулган аның территориясе халкы тарафыннан сайланган делегатларның өчтән ике өлешеннән ким булмаган кеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыручы гражданнарның конференцияләре, җыелышлары махсус вәкаләтлекләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнарының сметасын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының эшчәнлеге турында хисапны карап чыгу һәм раслау.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) шушы территориядә яшәүче халык ихтыяҗларын чагылдыра;

2) гражданнарның конференцияләре, җыелышларында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итә;

3) торак фондын тоту буенча хуҗалык эшчәнлеге, территорияне төзекләндерү, шушы территориядә яшәүче халыкның иҗтимагый-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән башка хуҗалык эшләрен, шушы гражданнарның акчаларына да, җирлекнең Башкарма комитеты белән төзегән килешү нигезендә җирлек бюджеты акчаларын кулланып та тормышка ашыра ала;

4) Җирлек Советына, Җирлек Башлыгына һәм Җирлек Башкарма комитетына бу органнар һәм җирле үзидарә органнарының, күрсәтелгән актларны кабул итү аларның компетенциясендә булган дәүләт хезмәтендәге затлар тарафыннан һичшиксез карап чыгарга тиешле муниципаль хокук актларының проектларын кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру, җирле бюджеттан тиешле акчаны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе бу Устав һәм җирлек Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә .

## 17нче маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру максатыннан халык, җирлекнең җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставы проектын эшләүне тормышка ашыручы һәм бу территориаль иҗтимагый үзидарә аның чикләрендә тормышка ашырылачак территориядә яшәүче халык җыелышын чакыруны оештыручы инициатив төркем оеша.

2. Гражданнар җыелышы җирлекнең тиешле территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләр буенча җирлек Советында гражданнар җыелышын тәкъдим итәчәк вәкилне (вәкилләрне) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә җирлек Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәгән вакыттан оешкан дип санала.

## 18нче маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышының вәкиле (вәкилләре) тарафыннан җирлек Башлыгына тапшырыла:

1) гражданнар җыелышының барлык вәкилләре тарафыннан имзаланган территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гариза;

2) һәр вәкилнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне һәм урыны, аны биргән органның исемен яки кодын күрсәтеп, паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, шулай ук һәр вәкилнең тору урыны адресы күрсәтелеп территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы беркетмәсе;

3) ике нөсхәдә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы.

2. Бу маддәнең 1нче пунктында күрсәтелгән документлардан кала, башка документларны таләп итү рөхсәт ителми.

Вәкилгә, исемлеген һәм аларны алу вакытын күрсәтеп, документларны алу турында расписка бирелә.

3. Җирлек Башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү турында документлар кергән көннән соң ике көн эчендә аны алдан карап чыгуны һәм уставны теркәү яки аны теркәүне кире кагу турында җирлек Советының карар проектын әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын алдан карап чыгуда һәм киңәш хокукы белән җирлек Советы утырышында катнашырга хокуклы.

5. Җирлек Советы территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү яки аны теркәүне кире кагу турында карарны бу маддәнең 1нче пунктында күрсәтелгән документларны җирлек Башлыгы алган көннән соң 30 көн эчендә карар кабул итә. Уставны теркәүдән баш тарту дәлилләнергә тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставы нормалары Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив хокук актлары, җирлек Уставы һәм башка муниципаль хокук актларына каршы килүе;

2) бу Уставның 16нчы маддәсенең 4нче пункты таләпләрен үтәмәү.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру максатка ярашлы булмаган дәлилләр буенча территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

8. Җирлек Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү мәсьәләсе буенча кабул ителгән дәлилләнгән карар өч көн эчендә язмача формада рәсми рәвештә гражданнар җыелышының вәкиленә (вәкилләренә) җиткерелергә тиеш.

9. Җирлек Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү карары кабул ителгән очракта уставның бер нөсхәсе, аны теркәү турында билге белән, гражданнар җыелышының вәкиленә бирелә, ә икенче нөсхәсе җирлек Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр җирлек Советы тарафыннан бу маддә белән билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны теркәгән көннән көченә керә.

**19нчы маддә. Авыл торак пункты старостасы**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм авыл торак пунктында яшәүчеләрнең үзара ярдәмләшүен оештыру өчен җирлектә урнашкан авыл торак пунктында урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишкәндә авыл торак пункты старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пункты старостасы, аның составына әлеге авыл торак пункты кергән җирлек Советы тарафыннан, авыл торак пунктында яшәүче гражданнар җыены тәкъдиме белән әлеге авыл торак пунктында яшәүче һәм актив сайлау хокукы булган кешеләр арасыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазифасын башкаручы, дәүләт граждан хезмәтен башкаручы, муниципаль вазифа һәм муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы шәхес була алмый, җирле үзидарә органнары белән хезмәт бәйләнешләрендә һәм алар белән башка турыдан-туры бәйләнештә була алмый.

4. Авыл торак пункты старостасы итеп түбәндәге шәхесләр билгеләнә алмый:

1) дәүләт вазифасын башкаручы, дәүләт граждан хезмәтен башкаручы, муниципаль вазифа һәм муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы;

2) суд тарафыннан эшкә яраксыз яки чикле эшкә яраклы дип табылучы;

3) ябылмаган яки алынмаган суд хөкеме булса.

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтле вакыты 5 ел. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре вакытыннан алда авыл торак пунктында яшәүче гражданнар җыены тәкъдиме белән аның составына әлеге авыл торак пункты кергән җирлек Советы карары тарафыннан, шулай ук бу Уставның 39нчы маддәсенең 1нче пунктының 1-7 кече пунктларында билгеләнгән очракларда туктатыла.

6. Авыл торак пункты старостасы аңа йөкләнгән мәсьәләләрне хәл итү өчен:

1) авыл торак пунктында урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча җирле үзидарә органнары белән, муниципаль предприятие һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән хезмәттәшлек итә, шул исәптән гражданнар җыенында, җыелышларда, конференцияләрдә катнашу юлы белән, мондый чараларның нәтиҗәләре буенча, шул исәптән муниципаль хокук актлары итеп рәсмиләштерелгән, җирле үзидарә органнары тарафыннан һичшиксез карап чыгарга тиешле мөрәҗәгатьләрне һәм тәкъдимнәрне җибәрә;

3) авыл торак пунктында яшәүчеләргә җирле үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча хәбәрләр җиткерә, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълуматларны аларга җиткерүдә булышлык итә;

4) җирле үзидарә органнарына халык алдында тыңлаулар һәм җәмәгать тыңлауларын оештыруда һәм үткәрүдә, авыл торак пунктында аларның нәтиҗәләрен халыкка җиткерүдә булышлык итә.

7. Авыл торак пункты старостасының эшчәнлеге һәм статусының башка мәсьәләләре гарантияләре җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп билгеләнә.

**20нче маддә. Ачык тыңлаулар, җәмәгать тикшерүләре.**

1. Әһәмиятле мәсьәләләр буенча муниципаль хокук актлары проектларын тикшерү өчен җирлек халкы катнашында Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы тарафыннан ачык тыңлаулар уздырылырга мөмкин.

2. Ачык тыңлаулар халык, Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы инициативасы буенча уздырыла.

Җирлек Советы яки халык инициативасы буенча уздырылган ачык тыңлаулар, Җирлек Советы тарафыннан, ә Җирлек Башлыгы инициативасы буенча-Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Ачык тыңлауларга түбәндәгеләр кертелә:

1) әлеге уставны бу норматив хокук актлары белән туры китерү максатыннан, муниципаль берәмлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль кануннар, Татарстан Республикасы конституциясе яки кануны кагыйдәнамәләрен төгәл күчермә формасында үзгәрешләр кертү очракларыннан кала, Җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокук акты проекты;

2) Җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Җирлекнең социаль –икътисад үсеше стратегиясе проекты;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунның 13нче маддәсенә туры китереп муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен

муниципаль берәмлек халкының гражданнар җыенында тавыш бирү юлы белән ризалыгын алу кирәк булган очрактан кала, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре;

5) территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, территорияне төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокук акты проекты.

4. Ачык тыңлаулар уздыру турында карар гамәлдәге канун һәм җирлекнең муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән срокларда кабул ителә.

5. Аларны уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, ачык тыңлаулар уздыру турында карар һәм ачык тыңлауларга кертелгән тиешле муниципаль хокук акты проекты гамәлдәге канун һәм җирлекнең муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән срокларда халыкка җиткерелергә тиеш.

6. Ачык тыңлаулар уздыру турында карарны бастырып чыгарган көннән алып аны уздыру көненә кадәр Җирлек халкы Җирлек Башлыгына язма рәвештә ачык тыңлауларга кертелгән мәсьәлә буенча тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен, шул исәптән ачык тыңлауларга кертелгән норматив хокук актлары проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәрен юнәлтергә хокуклы. Җирлек Башлыгы кертелгән тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне гомумиләштерә. Әлеге тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

7. Ачык тыңлаулар гамәлдәге канун, җирлекнең муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән срокларда уздырыла. Ачык тыңлаулар чакырылган белгечләр, экспертлар, кызыксынган затлар катнашында уза. Ачык тыңлауларда Җирлекнең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

8. Ачык тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре буенча, ачык тыңлауларга куелган муниципаль норматив хокук акты проектын кабул итү аларның компетенцияләренә караган җирле үзидарә органнары һәм җирлек дәүләт хезмәтендәге затлар тарафыннан тикшерелергә тиешле тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Ачык тыңлауларның нәтиҗәсе җирлекнең муниципаль норматив хокук акты һәм гамәлдәге канунда каралган срокларда халыкка җиткерелергә тиеш.

10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Җирлек Советы раслаган ачык тыңлаулар турында Кагыйдәнамә белән билгеләнә һәм җирлек халкына ачык тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль норматив хокук акты белән алдан таныштыруны, җирлек халкының ачык тыңлауларда катнашуын тәэмин итүче башка чараларны, кабул ителгән карарларны дәлилләүне кертеп, ачык тыңлау нәтиҗәләрен бастырып чыгарыруны (халыкка җиткерүне) күз алдында тотырга тиеш.

11. Җирлек үсеше генераль планнары проектлары, җирне куллау һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияләрне планлаштыру проектлары һәм территорияне мижалау проектлары, шулай ук шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлекләрен һәм капитал төзелеш объектларын куллануга рөхсәт бирү мәсьәләләре, рөхсәт ителгән төзелешнең тиешле параметрларыннан читкә китү мәсьәләләре, капитал төзелеш объектларын яңартып төзү буенча расланган җирне куллану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаса, ачык тыңлаулар һәм җәмәгать тикшерүләре уздырыла.

12. Бу маддәнең 10нчы пунктында күрсәтелгән нигезнамә буенча ачык тыңлауларны яки җәмәгать тикшерүләрен оештыру һәм уздыру тәртибе төзелеш эшчәнлеге турында канун кагыйдәнамәләрен исәпкә алып җирлек

Советы тарафыннан расланган ачык тыңлаулар турында Кагыйдәнамә белән билгеләнә.

**21нче маддә. Гражданнар җыелышы.**

1. Әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерү өчен, халыкны Җирлекнең җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге затлар һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән таныштыру өчен, территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру өчен җирлек территориясе бүлегендә гражданнар җыелышлары уздырыла ала. Гражданнар җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортларда уздырыла ала.

2. Гражданнар җыелышлары халык теләге буенча, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар җыелышлары Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар җыелышлары Җирлек Советы тарафыннан, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, җыелышта катнашырга хокуклары булган шушы территориядә яшәүче халык санының 10 процентыннан ким булмаган гражданнар төркеме, шушы территориядә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренең язмача тәкъдимнәре буенча билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турында тәкъдим карап чыгарга тиешле сораулар, җыелышны үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълуматны үз эченә алырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланырга тиеш, әгәр җыелышны үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать иткән булса-һәрберсенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны, адресы күрсәтелгән бу гражданнар тарафыннан имзалана.

Җирлек Советы гражданнар җыелышын үткәрү турында кертелгән тәкъдимне үзенең якындагы утырышында карый.

Җирлек Советы гражданнар җыелышын үткәрүне максатчан булмаган сәбәпләр буенча кире кагырга тиеш түгел.

5. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру максатыннан территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында һәм тикшерүгә куелган сораулар турында әлеге территория халкына җыелышны уздырганчы җиде көн алдан массакүләм мәгълумат чараларын, почта кәгазьләрен, фатирларны (ишегалларын) йөреп, игъланнар һәм башка чараларны кулланып хәбәр ителергә тиеш.

Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм үткәрүне Җирлек Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә 18 яше тулган, шушы территориядә яшәүче, сайлау хокукы булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны, Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе кысаларында муниципаль сайлаулар үткәргәндә

кулланылган тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү мәгълуматлары нигезендә билгеләнә.

Гражданнар җыелышы, җыелышта катнашу хокукы булган гражданнар санының өчтән бер өлешеннән ким булмаган кеше анда катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Җыелыш карары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затларга мөрәҗәгать кабул итә ала, шулай ук Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затлар белән үзара бәйләнештә гражданнар җыелышын тәкъдим итүче затларны сайлый ала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча уздырылган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән аларның компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышы белән кабул ителгән карарларны, аларның компетенцияләренә караган мөрәҗәгатьләрдә булган сорауларны чишү каралган җирле үзидарә органнары һәм Җирлек җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затлар карап чыгарга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын әзерләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль канун, әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышының нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 22нче маддә. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерү кирәк булган очракта һәм барлык Җирлек халкы вәкилләренең фикерен ачыклау өчен үткәрелә.

Җирлек территориясендә яшәүче халык арасыннан булган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), гражданнар җыелышын чакыру кыенлашкан вакытта, шул исәптән шушы территориядә яшәүче гражданнар җыелышында катнашырга хокукы булган халык саны 100 кешедән артып китсә, үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтен тормышка ашыра.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык теләге буенча, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) сайланган делегатларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашкан делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышы) билгеләү һәм уздыру тәртибе, делегатларны сайлау әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру белән бәйле булган мәсьәләләр буенча гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән каралган тәртиптә һәм очракта билгеләнә һәм үткәрелә.

7. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**23нче маддә. Гражданнарны сораштыру**

1. Гражданнарны сораштыру Җирлекнең бөтен территориясендә яки бер өлешендә, җирле үзидарә дәүләт хезмәтендәге затлар, шулай ук дәүләт власте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдимнәр характерында була.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукы булган Җирлек халкы катнаша ала.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәге инициативалар буенча үткәрелә:

1) Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы – әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары – республика һәм регионара әһәмиятле объектлар өчен Җирлек җирләрен максатчан куллануны үзгәртү буенча карарлар кабул иткәндә халык фикерен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе Җирлек Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карар Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында Җирлек Советы карарында күрсәтелә:

1) сораштыруны үткәрү вакыты һәм датасы;

2) сораштыруны үткәрү вакытында тәкъдим ителәчәк сорау (сораулар) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру бите формасы;

5) сораштыруда катнашкан Җирлек халкының минималь саны.

6. Җирлек халкы гражданнарны сораштыру үткәрү турында аны үткәргәнче 10 көн алдан хәбәр ителергә тиеш.

7. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру белән бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләр белән тормышка ашырыла:

1) Җирлек бюджеты акчасы хисабына-Җирлек җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру үткәрелгән очракта;

2) Татарстан Республикасы бюджеты хисабына - Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәрелгән очракта.

8. Сораштыру нәтиҗәләре ул уздырылганнан соң бер ай эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән Җирлекнең теләсә кайсы кешесе танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре Җирлекнең җирле үзидарә органнары тиешле карарларны кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

**24нче маддә. Гражданнар җыены**

1. Гражданнар җыены халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыруда катнашу формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль кануны һәм җирлекнең муниципаль норматив хокук акты белән каралган очракларда үткәрелә.

3. “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунның 25.1 маддәсендә каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелә ала:

1) күрсәтелгән торак пункт аның составына кергән җирлек чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән торак пункт территориясе башка җирлек территориясенә күчергә мөмкин булган очракта, торак пунктта;

2) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча әлеге торак пункт территориясендә җирлек составына кергән торак пунктта;

3) авыл халкы аз яшәгән территориядә урнашкан яки кыен җирләрдә, бу җирлектә яшәүчеләр саны 100дән ким булган җирлектә җирлекне бетерү турында мәсьәлә буенча;

4) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасына кандидатура күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу турында мәсьәлә буенча;

5) авыл торак пунктында гражданнар җыены Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турында канунда каралган очракта муниципаль хезмәт вазифаларын алыштыруга конкурс уздырган вакытта конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатыннан уздырыла.

4. Гражданнар җыены җирлек башлыгы яки сайлау хокукы булган, 10 кешедән дә ким булмаган авыл торак пункты халкының бер төркеме инициативасы буенча җыела ала.

5. Җыен үткәрү инициативасына ярдәм итү өчен җыерга кирәк булган имзаларның саны сайлау хокукы булган, даими яки күбесенчә яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 25 имзадан да ким булмаган гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә.

6. Җирлек башлыгы тарафыннан җыелган халык җыены җирлек башлыгы карары белән, инициатив төркем тарафыннан җыелган җыен җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пункт халкына алдан ук гражданнар җыенын үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр ителә, алдан ук муниципаль хокук акты проекты һәм гражданнар җыены карарына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар белән таныштырылалар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокук актлары булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары реестрына кертелергә тиеш.

**25нче маддә. Җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнарына гражданнар шәхси һәм коллектив мөрәҗәгать итергә хокуклы.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен тикшерү тәртибе турында” 2нче май, 2006нчы ел, №59-ФЗ Федераль канунында, “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12нче май, 2003нче ел, №16-ЗРТ Татарстан Республикасы Кануны билгеләгән тәртиптә һәм вакытта каралырга тиеш.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен тикшерү тәртибен һәм вакытын бозган өчен җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннарына туры китереп җаваплы булалар.

**26нчы маддә. Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруның башка формалары һәм аны тормышка ашыруда катнашуы**

1. Федераль канунга туры китереп, әлеге Устав белән каралган, җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыру формалары һәм аны тормышка ашыруда катнашуы белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга, Татарстан Республикасы кануннарына каршы килми торган башка формаларын тормышка ашыруда катнаша ала.

2. Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруы һәм аны тормышка ашыруда катнашуы закончылык һәм ихтыяри принципларына нигезләнә.

Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары халыкка Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруында һәм аны тормышка ашыруда катнашуында ярдәм итергә тиеш.

**IIIнче бүлек. Җирлек Советы.**

**27нче маддә. Җирлек Советы - Җирлекнең җирле үзидарәсенең сайлап куелган органы**

1. Җирлек Советы - җирле үзидарәнең даими гамәлдәге коллегиаль сайлап куелган органы булып тора.

2. Җирлек Советының рәсми исеме – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Советы.

3. Җирлек Советының вәкаләтлек вакыты-5 ел.

4. Җирлек Советы районда яшәүчеләр белән хисаплашырга һәм контрольдә булырга тиеш.

5. Җирлек Советының мөһере һәм үзенең атамалары белән бланклары бар.

6. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыруга тотылган акча Россия Федерациясе чыгымнар классификациясенә туры китереп җирлек бюджетында аерым юл белән карала.

**28нче маддә. Җирлек Советы составы**

1. Җирлек Советы муниципаль сайлауларда сайлап куелган 10 депутаттан тора.

2. Җирлек Советы аның составына Җирлек Советы билгеләгән саннан өчтән ике өлештән ким булмаган депутатларны сайлаганда хокуклы була.

**29нчы маддә. Җирлек Советы депутаты статусы**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре аны сайлап куйган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Җирлек Советы эшен башлаган көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, бу Устав белән билгеләнгән очраклардан кала, азат ителмәгән эшкә таянып депутат эшчәнлеген төп эш урынындагы хезмәт вазифалары белән берләштереп алып бара.

3. Җирлек Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль кануннар белән билгеләнә.

4. Җирлек Советы депутатына үзенең вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен кануннар, бу Устав, Җирлек Советы карарына туры китереп шартлар тудырыла.

5. Җирлек Советы депутаты Җирлек Советы раслаган депутат этикасы Кагыйдәләрен, шул исәптән түбәндәге йөкләмәләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелып торырга һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, оешмаларга, вазифаи затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм гражданнарга, аларның туганнарына яки үзләренә кагылышлы мәсьәләләрне чишкәндә, депутат статусын кулланып, йогынты ясарга тиеш түгел;

2) депутат вазифаларын объектив башкаруда шикләнүләр туганда эш – гамәлләреннән тыелып торырга тиеш, шулай ук Җирлек Советы дәрәҗәсенә яки абруена зыян китерергә сәләтле булган конфликт ситуацияләрне булдырмый калырга тиеш;

3) конфликт ситуацияләре килеп чыгу куркынычы туган очракта, депутат вазифаларын башкаруга комачаулык иткән шәхси кызыксынулар тәэсир итә яки тәэсир итергә мөмкин булган очракта, Җирлек Советына хәбәр итергә һәм аның әлеге конфликт ситуацияләрне булдырмый калдыруны яки җайлауга юнәлтелгән карарларын үтәргә тиеш;

4) Җирлек Советы урнаштырган халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә тиеш;

5) федераль кануннарга туры китереп, конфидинциаль характердагы мәгълуматларга караган мәгълуматларны, Җирлек Советы Депутаты вазифаларын башкарган вакытта депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган үзенә билгеле булган мәгълуматны таратырга һәм шул максатларда кулланырга тиеш түгел;

6) депутат вазифаларын башкару аркасында физик һәм юридик затлардан бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, булышлык, күңел ачулар, яллары, трансполрт чыгымнары өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алмаска тиеш.

6. Депутат, җирле үзидарәнең сайлау органы заты, җирле үзидарә органының дәүләт хезмәтендәге заты “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны һәм башка федераль кануннарда билгеләнгән тәртиптә чикләүләр һәм тыюларны сакларга һәм

вазифаларын үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайлау органы затының, җирле үзидарә органының дәүләт хезмәтендәге затының вәкаләтләре, муниципаль вазифа башкаручы башка затларның вәкаләтләре “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт (вклад) ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм (яки) куллануны тыю турында” 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме белән чыгымы туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ Федераль канунында билгеләнгән тәртиптә чикләүләр һәм тыюларны сакламаган һәм вазифаларын үтәмәгән очракта туктатыла.

7. Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында кануны белән туры китереп җирлек Советы депутатының керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълуматларының дөреслеге һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы кануны билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча үткәрелә.

8. Бу маддәнең 7нче өлешенә туры китереп үткәрелгән тикшерү вакытында “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт (вклад) ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм (яки) куллануны тыю турында” 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме белән чыгымы туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ Федераль канунында билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны саклмау һәм вазифаларын үтәмәү турында фактлар ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты тиешле карар кабул итү өчен җирлек Советына, яки судка җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гаризасы белән мөрәҗәгать итә.

9. Муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы шәхеснең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар Югары Ослан муниципаль җирлеге рәсми сайтында мәгълумати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә һәм (яки) муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә массакүләм мәгълумат чараларында урнаштырыла.

10. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары бинада, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук аларны үткәрү тормышны тәэмин итү объектларының, транспорт һәм иҗтимагый инфраструктура, элемтә эшчәнлеген бозуга китермәгән, җәяүлеләр һәм транспорт йөрешенә, яки гражданнарның торак йортларга, транспорт һәм иҗтимагый инфраструктура объектларына керү юлларында комачаулык тудырмаган шартларда, ишегаллары эчендәге территорияләрдә үткәрелә. Мондый очрашулар турында тиешле муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына белдерү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга алдан ук аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итергә хокуклы.

11. Җирле үзидарә органнары сайлаучылар белән очрашу үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук җирле үзидарә

органнары тарафыннан сайлаучылар белән очрашу өчен бирелгән биналарның исемлеген һәм аларның бирелү тәртибен билгелиләр.

12. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турында Россия Федерациясе кануны белән туры китереп халык алдындагы чара формасында үткәрелә.

13. Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турында Россия Федерациясе кануны белән туры китереп депутатның халык алдындагы чара формасында оештырылган һәм үткәрелгән сайлаучылар белән очрашуларына каршы килүгә Россия Федерациясе кануны белән туры китереп административ җаваплылык каралган.

**30нчы маддә. Җирлек депутатының, Җирлекнең җирле үзидарә органының сайлап куелган әгъзаның, җирлекнең җирле үзидарә органының сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең вәкаләтләрен тормышка ашыру гарантияләре**

1. Җирлек депутатының, җирле үзидарә органының сайлап куелган әгъзаның, җирле үзидарә органының сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең вәкаләтләрен тормышка ашыру гарантияләре федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп Җирлек Уставы белән билгеләнә.

2. Даими нигездә муниципаль вазифа башкарган кешегә түбәндәге гарантияләр бирелә:

1) муниципаль хокук актлары белән туры китереп дәүләт хезмәтендәге вәкаләтләрен башкаруны тормышка ашыру өчен уңай шартлар;

2) канунга туры китереп, милек формаларына карамастан, Җирлек бюджеты хисабыннан тулысынча яки өлешчә финансланган, яки канун белән туры китереп салым һәм мәҗбүри бурычларын түләү буенча ташламалары булган җирле үзидарә органнарының, предприятие, учреждение һәм оешмаларның дәүләт хезмәтендәге кешеләре тарафыннан беренче чиратта кабул итү хокукы;

3) җирле үзидарә органнары кабул иткән хокук актларына тоткарлыксыз керүгә хокук;

4) Җирлек муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә, Җирлек территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнарыннан әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруга кирәк булган мәгълумат алырга, ә федераль кануннар белән каралган очракта – барлык милек формалары булган оешмалардан, җәмәгать оешмаларыннан һәм аларның дәүләт хезмәтендәге кешеләреннән мәгълумат алырга хокук;

5) вакытында һәм тулы күләмдә акчалата түләү алуга хокук;

6) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән тәэмин ителгән ял, ял көннәре һәм бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле төп һәм өстәмә ялга хокук;

7) муниципаль вазифа башкарган кешегә һәм аның гаиләсенә, шул исәптән муниципаль вазифа башкарган кеше пенсиягә чыкканнан соң медицина ярдәме күрсәтү;

8) муниципаль вазифа башкарган кешегә, үзенең вазифасын башкарган вакытта хезмәткә яраклылыгын югалткан очракта дәүләт социаль страхованиесенә;

9) Уставта билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, муниципаль вазифа башкарган кеше пенсия белән тәэмин ителергә, шулай ук федераль кануннарга туры китереп, муниципаль вазифа башкарган кеше, үзенең вазифасын башкарган вакытта үлгән очракта, аның гаиләсен пенсия белән тәэмин итү хокукы;

10) федераль кануннар белән, Җирлекнең муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә, шартларда һәм очракта үзенең вазифасын башкарган вакытта көчләү, янаулар һәм башка аның хокукларын бозган гамәлләрдән муниципаль вазифа башкарган кешене һәм аның гаиләсен яклау;

11) эш буенча командировкалар белән бәйле чыгымнарны каплау;

12) Җирлекнең муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә, үзенең вазифасын башкарган вакытта транспорт белән тәэмин итү, шулай ук эш буенча шәхси транспортын кулланган өчен компенсация .

3. Даими булмаган нигездә муниципаль вазифа башкарган кешегә әлеге маддәнең 1нче пунктының 1-4 һәм 10нчы кече пунктларында каралган гарантияләр бирелә, шулай ук Җирлекнең муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә эш буенча командировкалар белән бәйле чыгымнарнын компенсацияләү каралган.

4. Муниципаль вазифа башкарган кешеләргә вазифаларын башкару гарантиясе Җирлек бюджеты хисабына финанслана.

**31нче маддә. Җирлек Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук Җирлек териториясендә урнашкан күмәк хуҗалыклар, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар белән элемтәдә тора.

2. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм аларга отчёт бирә.

3. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында үзенең башкарган эшләре буенча елга бер тапкырдан да ким булмаган хисап тота, аларны Җирлек Советы эшчәнлеге белән даими таныштырып тора, шулай ук айга бер тапкырдан да ким булмаган халыкны кабул итү алып бара.

4. Җирлек Советы депутаты канунда каралган буенча Җирлек халкының законлы хокукларын, иреген һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча, шул исәптән алардан килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карап чыгырга һәм аларның сорауларының вакытында чишелеше буенча дөрес чаралар күрергә тиеш.

**32нче маддә. Яңа сайланган Җирлек Советы эшен оештыру**

1. Яңа сайланган Җирлек Советы беренче утырышына Җирлек Советы депутатларның өчтән ике өлеше составында сайланган көннән соң 10 көннән соңга калмыйча җыела.

2. Сайлаулардан соң Җирлек Башлыгын сайлаганчы Җирлек Советының беренче утырышын Җирлек Советының яше буенча олырак булган депутат ача һәм алып бара.

**33нче маддә. Җирлек Советы компетенциясе.**

1. Җирлек Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) Җирлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) Җирлек территориясендә канунга туры китереп гомумүтәлешле кагыйдәләр булдыру;

3) Җирлек бюджетын һәм аның үтәлеше турында отчётны раслау;

4) Россия Федерациясенең салымнар һәм җыелган акчалар турындагы канунга туры китереп җирле салымнар һәм җыелган акчалар, аларны түләү буенча ташламалар бирелүне булдыру, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

5) Җирлекнең социаль – икътисади үсеш стратегиясен раслау;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләр буенча җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системасының комплекслы үсеш программаларын, җирлекнең транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеш программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасы системасының комплекслы үсеш программаларын раслау;

7) Җирлекнең чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору буенча инициатива белән чыгу;

8) Җирлек Советына депутатлар сайлауны билгеләү һәм Җирлек Советы депутатларын сайлау буенча сайлау округлары схемаларын раслау;

9) җирле референдумны билгеләү;

10) Җирлек Башлыгын билгеләү;

11) Җирлек Башлыгы урынбасарын билгеләү;

12) җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын раслау, җирлекнең һәрбер җирле үзидарә органының эчке структурасын һәм штат расписаниесен раслау;

11) Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына керү буенча конкурс үткәрү тәртибен билгеләү, конкурс комиссиясе әгъзаларын раслау;

12) муниципаль җирлек Советына җирлек Советы депутатлары арасыннан җирлек вәкилен сайлау ;

13) Җирлек Сайлау комиссиясе әгъзаларын раслау;

14) Җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору буенча сорауларны тавышка куюны билгеләү, Җирлек Советы депутаты чакыруы буенча тавыш бирү;

15) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру;

16) Җирлекнең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм куллану тәртибен билгеләү, шул исәптән федераль канунга туры китереп аларны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; Җирлек Советы раслауыннан соң яки килешү буенча тартып алынган муниципаль мөлкәт төрләренең исемлеген билгеләү;

17) муниципаль предприятие һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртү һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү, шулай ук федераль канунда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтенә тарифларны кую тәртибен һәм аларны куюны билгеләү;

18) җирлекнең муниципальара хезмәттәшлекне оештыруда катнашу тәртибен билгеләү;

19) җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең материаль - техник тәртибен һәм оештыруны булдыруны билгеләү;

20) Җирлекнең Ревизия комиссиясен фрмалаштыру;
21) җирлек башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү ;
22) Җирлекнең җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлап куелган затларының урындагы мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрен үтәүне тикшерү;
23) җирлек территориясен төзекләндерү һәм тәртиптә тоту кагыйдәләрен раслау;
24) җирлекнең территориаль планлаштыру документларын, җирлекнең төзелешне проектлауның җирле нормативларын, җирлек территориясендә җирләрдән файдалану, һәм төзелешне, җирлекнең генераль планын раслау, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китереп башка төзелеш документларын раслау;
25) җирлек территориясендә урамнарга һәм торак пунктларның башка өлешләренә исемнәр бирү һәм исемнәрен үзгәртү ;
26) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм материаль ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм куллану тәртибен билгеләү;
27) специальләшкән муниципаль торак фондының торак йортларын бирү тәртибен билгеләү ;
28) җирлек бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына кирәкле акчаны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;
29) автоном коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар формасында коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карар кабул итү ;
30) үзенең массакүләм мәгълумат чараларын оештыру;
31) Җирлек Уставын һәм Җирлек Советы карарларын аңлату;
32) үзенең эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Җирлек Советы Регламентын һәм башка карарларны кабул итү;
33) Җирлек Советы турында Кагыйдәнамәне раслау;
34) федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннарына буйсынган муниципаль районнарның сайлап куелган органнарына бирелгән башка вәкаләтләре, шулай ук бу Устав тарафыннан Җирлек Советы компетенциясенә буйсынган башка вәкаләтләре.
федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннарына буйсынган муниципаль җирлекнең сайлап куелган органнарына бирелгән башка вәкаләтләре, шулай ук бу Устав тарафыннан Җирлек Советы компетенциясенә буйсынган башка вәкаләтләре.
2. Җирлек Советы Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең эшчәнлеге нәтиҗәләре, Җирлек Башлыгына караган башка җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында, шул исәптән Җирлек Советы күтәргән мәсьәләләрне чишү турында еллык отчётын тыңлый.

**34нче маддә. Җирлек Советының эшләү тәртибе**

1. Җирлек Советының эшләү тәртибе бу Устав һәм Җирлек Советы Регламенты белән билгеләнә.
2. Җирлек Советының төп эш формасы булып аның Җирлек компетенциясенә кагылышлы сорауларны чишә торган утырышлары тора.
3. Әгәр Җирлек Советы утырышында сайлап куелган депутатларның 50 проценттан кимерәге катнашмаса, ул хокуклы дип санала.
4. Җирлек Советының чираттагы утырышы кирәк булганда, ләкин кимендә өч айга бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш утырышлар Җирлек

Башлыгы яки Җирлек Советының билгеләнгән депутатларның кимендә өчтән бер өлеше санынча депутатлар төркеме инициативасы буенча чакырыла.

5. Совет утырышлары Җирлек Башлыгы тарафыннан чакырыла. Җирлек Советы депутатлары һәм чакырылган затлар киләсе утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе белән биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырышка –аны үткәрергә бер көн кала хәбәрдар булырга тиешләр.

6. Җирлек Советы утырышлары ачык һәм белдереп үткәрелә. Җирлек Советының ачык утырышларында Җирлекнең теләсә кайсы кешесе катнаша ала.

Регламент белән каралган очракта, Җирлек Советы ябык утырышлар үткәрү турында карар кабул итергә хаклы, һәм анда Җирлек Советы чакырган затлар гына, шулай ук кануннарга туры китереп утырышта катнашырга хокукы булган затлар катнаша ала.

7. Җирлек Советының һәрбер утырышы беркетмәгә теркәлә һәм язып барыла. Җыелыш беркетмәсенә җыелышның датасы, үткәрү урыны, үткәрү вакыты турында мәгълумат, каралачак барлык сораулар саналып чыга һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен күрсәтеп барлык кабул ителгән карарлар теркәлә. Җирлек Советы җыелышы беркетмәсенә Җирлек Башлыгы кул куйганнан соң, аның белән Җирлекнең теләсә кайсы кешесе таныша ала.

8. Җирлек Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Җирлек Советы депутаты тавыш бирүгә хокукын үзе башкара. Җирлек Советында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм ябык була ала. Һәр төр тавыш бирүне куллану бу Устав, Җирлек Советы Регламенты белән билгеләнә.

### 35нче маддә. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру

1. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыруны Җирлек Башлыгы башкара.

2. Җирлек Советы Регламентына туры китереп Җирлек Советы компетенциясенә караган сорауларны алдан карау һәм әзерләү өчен Җирлек Башлыгыннан һәм аның урынбасарыннан кала депутатлардан Җирлек Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комитет оештырыла, шулай ук даими һәм вакытлы комиссияләр оештырылырга мөмкин. Депутат ике даими комиссиядә генә эшләргә хокуклы.

3. Муниципаль программаларны, Җирлек Советы карарлары проектларын әзерләү өчен, Җирлеккә кагылышлы әһәмиятле сорауларны тикшерү өчен, Җирлек Советы каршында аның карары буенча депутатлар, Җирлек Башкарма комитеты вәкилләре, иҗтимагый оешмалар, организацияләр һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм Җирлек халкы составында, партия фракцияләре, эшче, эксперт һәм башка киңәш итүче төркемнәр оеша ала.

### 36нчы маддә. Җирлек Советының контроль функцияләрне тормышка ашыруы

1. Җирлек Советы Җирлек территориясендә бу Уставның кагыйдәнамәләре үтәлешен, Җирлек Советы кабул иткән норматив актлар, Җирлек бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш акчаларны куллану, Җирлекнең үсеш программаларын, Җирлек Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка органнары эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыра.

2. Җирлек җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары кануннарны, бу Уставны һәм башка муниципль хокук актларын бозган очракта, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы карары нигезендә билгеләнгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләр оешырга мөмкин.

3. Кануннарга яраклаштырып Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы карары нигезендә Җирлек бюджеты акчаларының максатчан кулланылышын тикшерү (ревизия), муниципаль мөлкәтнең нәтиҗәле кулланылышын тикшерә ала, шулай ук Җирлек Башкарма комитетының башка финанс-хуҗалык мәсьәләләрен тикшерү үткәрә ала. Тикшерү (ревизия) үткәрергә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарыннан белгечләр, бәйсез аудиторлар җәлеп ителә ала.

4. Җирлек Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазифаи затлар, канун белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, Җирлек Советы, аның контроль коиссияләре, Җирлек Советы депутаты мөрәҗәгате буенча соратып алынган Җирлек Советын җитәкләү белән бәйле мәгълуматны бирергә тиеш, ә кануннарны, муниципаль хокук актларын бозу очраклары ачыкланса, җитешсезлекләрне бетерү өчен һәм гаеплеләрне җавапка тарту буенча кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Җирлек Советы Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең эшчәнлеге нәтиҗәләре, Җирлек Башлыгына караган башка җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында, шул исәптән Җирлек Советы күтәргән мәсьәләләрне чишү турында еллык отчётын тыңлый.

6. Җирлек Советы, контроль функцияләрен тормышка ашырганда, Җирлек Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-күрсәтмә бирү эшчәнлегенә катнашырга хокуклы түгел.

**37нче маддә. Җирлекнең муниципаль Советына җирлек вәкилен сайлау.**

1. Югары Ослан муниципаль район Советына җирлек вәкиле Җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

2. Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кандидат сайланган булып санала.

**38нче маддә. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 73нче маддәсе белән каралган тәртиптә һәм нигездә Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

Җирлек Советы вәкаләтләре шулай ук түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) җирлек Советы үз-үзен тарату турында карар кабул иткән очракта;

2) Татарстан Республикасы Югары судының Җирлек Советы депутатлар составының хокуксыз булуы турында карары көченә кергәч, шул исәптән депутатлар үзләренең вәкаләтләрен өстеннән төшерсә;

3) федераль кануннарга туры китереп тормышка ашырылган, Җирлекне үзгәртеп кору булган, шулай ук Җирлекне бетергән очракта;

4) шәһәр округы белән берләштәрү аркасында җирлекнең муниципаль берәмлек статусын югалтуы;
5) Җирлек чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, яки җирлекне шәһәр округы белән берләштерү аркасында килеп чыккан сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә;
6) гражданнарның туры ихтыяры юлы белән кабул ителгән карарларны тормышка ашыру өчен кирәк булган муниципаль хокук актларын чыгару вакыты бозылса.
2. Җирлек Советы вәкаләтенең вакытыннан алда туктатылуы аның депутатларының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуына сәбәп була.
3. Җирлек Советы вәкаләте вакытыннан алда туктатылган очракта вакытыннан алда сайлаулар федераль канун белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

**39нчы маддә. Җирлек Советының үз-үзен тарату турында карар кабул итү тәртибе**

1. Җирлек Советының үз-үзен тарату турында карары Җирлек Башлыгы яки Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган депутатлар төркеме инициативасы буенча кабул ителә ала.
2. Үз-үзен тарату турында карар кабул итү инициативасы күрсәтелә алмый:
1) Җирлек Советын сайлаганнан соң беренче елы эчендә;
2) Җирлек бюджеты кабул ителгән һәм аның үтәлеше турында отчёт расланган вакытта;
3) яңа Җирлек Башлыгын сайлаганчы Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта.
3. Җирлек Советының үз-үзен тарату турында язмача тәкъдиме үз-үзен тарату сәбәпләрен күрсәтергә тиеш, шулай ук аңа үз-үзен тарату сәбәпләрен дәлилләгән материаллар куелырга тиеш.
4. Үз-үзен тарату турында сорауны алдан карап чыгу буенча Җирлек Советы депутатлары саныннан комиссия төзелә. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы карары буенча Җирлек Советының үз-үзен тарату турында мәсьәләсе халык тыңлауларына куелырга мөмкин.
5. Җирлек Советының үз-үзен тарату турында мәсьәләне карау дәвамлылыгы Җирлек Советы депутатлары һәм Җирлек халкы тарафыннан үз-үзен тарату инициативасының барлык шартлары һәм нигезләрен һәр яклап һәм объектив тикшерү мөмкинлегенә гарантия бирергә тиеш. Үз-үзен тарату турында карар үз-үзен тарату инициативасы күрсәтелгән көннән алып ике ай узганнан соң кабул ителә ала.
6. Җирлек Советының үз-үзен тарату турында карары яшерен тавыш бирү юлы белән Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән ике өлеш тавыш белән кабул ителә.
7. Җирлек Советы тарафыннан үз-үзен тарату турында тәкъдиме кире кагылса, кабат үз-үзен тарату турында инициатива үз-үзен тарату мәсьәләсе буенча тавыш биргән көннән алып бер елдан да иртәрәк була алмый.

**40нчы маддә. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:
1) үлгән очракта;
2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;
3) суд тарафыннан хезмәткә яраксыз яки чикле эшкә яраклы дип табылса;
4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;
5) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;
6) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;
7) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины җирле үзидарә органнарына сайлана ала;
8) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынса;
9) Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса;
10) хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә алынса;
11) федераль канунда билгеләнгән башка очракларда.

2. Үзенең вәкаләтләрен башкаручы Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канун билгеләгән чикләүләрне үтәмәгән очракта туктатыла.

3. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен туктату турындагы карары бу маддәнең 1нче өлешенең 1-7,10нчы пунктларында күрсәтелгән очракларда депутат вәкаләтләре туктатылган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу очрак җирлек Советы сессияләре арасында булса, өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

4. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре бу маддәнең 1нче өлешенең 8нче пунктларында күрсәтелгән очракларда җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен рәсми рәвештә бастырып чыгарган көннән соң туктатыла.

5. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре бу маддәнең 1нче өлешенең 9нчы пунктларында күрсәтелгән очракларда җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән туктатыла.

6. Татарстан Республикасы Президенты җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта вәкаләтләрне вакытыннан алда туктатуга нигез булып җирлек Советына әлеге гариза кергән көн санала.

7. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, депутатны өстәмә сайлаулар федераль канун, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән туры китереп билгеләнә.

## IV нче бүлек. Җирлек башлыгы

**41нче маддә. Җирлек Башлыгы – Җирлекнең югары дәүләт хезмәтендәге шәхесе**

1. Җирлек Башлыгы Җирлекнең югары дәүләт хезмәтендәге шәхесе булып тора.

2. Җирлек Башлыгы Җирлек Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара.

3. Җирлек Башлыгы вазифасының рәсми исеме-Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы.

4. Җирлек Башлыгы вазифасы буенча Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советы депутаты була.

**42нче маддә. Җирлек Башлыгын сайлау тәртибе**

1. Җирлек Башлыгы яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында Җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән Җирлек Советы вәкаләте вакытына сайлана.

2. Җирлек Башлыгын сайлау Җирлек Советы депутатлары күрсәткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән Җирлек халкы, иҗтимагый оешмалар, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә сайлана.

3. Сайланганнан соң Җирлек Башлыгы түбәндәгечә ант бирә:
“Миңа йөкләнгән Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгының зур бурычларын тормышка ашырганда Россия Федерациясе кануннарын һәм Конституциясен, Татарстан Республикасы кануннарын һәм Конституциясен, Югары Ослан авыл җирлеге Уставын үтәргә, Югары Ослан авыл җирлеге кешеләренең мул тормышын тәэмин итү өчен бөтен белемемне һәм көчемне куярга, кеше һәм гражданин хокукларын сакларга ант итәм”.

**43нче маддә. Җирлек Башлыгының статусы**

1. Җирлек Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Җирлек Башлыгын Югары Ослан муниципаль районы Советына даими нигездә башкаручы вазифага сайланган очракта, ул җирлек Башлыгы вазифаларын азат ителмәгән нигездә тормышка ашыра.

3. Җирлек Башлыгы үзенең эшчәнлегендә, бу Устав һәм федераль канунга туры китереп, Җирлек Советына һәм Җирлектә яшәүче халык контрольлегендә һәм отчётында .

4. Җирлек Башлыгы елга бер тапкыр Җирлек Советына үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән җирлек Советы куйган мәсьәләләрне чишү турында еллык отчётларын тәкъдим итә.

5. Җирлек Башлыгы “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт (вклад) ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм (яки) куллануны тыю турында” 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме белән чыгымы туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ Федераль кануны, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канун һәм башка федераль кануннар билгеләгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә һәм вазифаларын башкарырга тиеш.

**44нче маддә. Җирлек Башлыгының вәкаләтләре**

Җирлек Башлыгы:

1) башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, дәүләт хакимияте органнары белән, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәттә Җирлек исеменнән эш алып бара, Җирлек исеменнән ышаныч язуыннан башка эш йөртә;

2) Җирлек Советы эшен оештыра, Җирлек Советы утырышларын җыя һәм аларда рәислек итә, җирлек Советы утырышының чираттан тыш чакырылышын таләп итергә хокуклы;

3) үзенең вәкаләтләре кысаларында Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокук актлары чыгара;

4) бу Устав белән билгеләнгән тәртиптә, Җирлек Советы кабул иткән норматив хокук актларына кул куя һәм халыкка җиткерә, шулай ук Җирлек Советы утырышлары беркетмәләренә кул куя;

5) Җирлек Советы эшчәнлегендә җәмәгатьчелек фикерен исәпләү һәм ачыклык булдыру буенча чаралар күрә;

6) халыкны кабул итә, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

7) Җирлек бюджетында каралганча, Җирлек акчасы белән идарә итә, шул исәптән Җирлек Советы эшчәнлеген тәэмин итү һәм тотуга акчаларны бүлүче булып тора, банк учреждениеләрендә җирлекнең бюджет һәм башка счётларын ача һәм яба;

8) Җирлек Советы контроль вәкаләтләрен тормышка ашыруны көйли;

9) канунга һәм бу Уставка туры китереп, халыкның үз ирке белән кабул ителгән карарларын тормышка ашыру буенча Җирлек Советының хокук актларын кабул итүне оештыра;

10) Җирлек Советы карауына җирлек бюджеты проектын һәм аның үтәлеше турында отчётны, җирлек үсеше программалары һәм план проектлары һәм аларның үтәлеше турында отчётны тапшыра;

11) Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Татарстан территориясендә эшләп килүче башкарма хакимият федераль органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнешен булдыра;

12) Җирлек Советының муниципаль хезмәткәрләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру чараларын һәм дисциплинар җаваплылыкны куллана;

13) Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

14) Җирлек исеменнән дәүләт хакимияте органнары белән, башка муниципаль берәмлекләр белән икътисад һәм иҗтимагый-мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүнамәләр һәм килешүләр төзи, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнеш турында һәм гамәлләрне килештерү турында килешүнамәләр һәм килешүләр төзи;

15) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруны булдыра;

16) муниципаль берәмлекләр башлыкларының идарә итүе турында федераль кануннар белән, Татарстан Республикасы кануннары белән бирелгән башка вәкаләтлекләрне, шулай ук бу Устав, Җирлек Башлыгы компетенциясенә караган Җирлек Советы карарлары белән бирелгән башка вәкаләтлекләрне тормышка ашыра.

**45нче маддә. Җирлек Башлыгы Ярдәмчесе**

1. Җирлек Башлыгы тәкъдиме буенча Җирлек Советы тарафыннан депутатлар арасыннан Җирлек Башлыгы ярдәмчесе сайлана.

2. Җирлек Советы депутаты Җирлек Башлыгы ярдәмчесе булып, аны сайлау өчен Җирлек Советы депутатларының яртысыннан артык өлеше тавыш биргән булса, сайланган дип санала.

3. Җирлек Башлыгы ярдәмчесе Җирлек Советы Регламенты билгеләгән вазифаларны бүлү белән туры китергән функцияләрне, Җирлек Башлыгы йөкләмәләрен башкара, ә ул вакытлыча булмаган очракта (авыру яки ялы сәбәпле) яки ул үз вазифаларын башкара алмаган очракта яки вакытыннан алда вәкаләтләре туктатылганда, Җирлек Башлыгы вазифаларын башкара.

4. Җирлек Башлыгы ярдәмчесе үзенең вәкаләтләрен азат ителмәгән нигездә тормышка ашыра.

5. Җирлек Башлыгы ярдәмчесе вәкаләтләре вакытыннан алда бу Уставның 39нчы маддәсендә каралган нигездә вакытыннан алда туктатыла.

6. Җирлек Башлыгы ярдәмчесе Җирлек Башлыгы инициативасы буенча кабул ителгән Җирлек Советы карары белән яки Җирлек Советы депутатлары арасыннан өчтән бер өлешеннән ким булмаган төркемнең таләбе буенча теләсә кайсы вакытта вазифасыннан чакыртып алына ала. Җирлек Башлыгы ярдәмчесен чакыртып алу турында карар Җирлек Советы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

**46нчы маддә. Җирлек Башлыгы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы**

1. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз ризалагы белән отставкага китсә;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунның 74нче маддәсенә туры китереп отставкага җибәрелсә;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунның 74нче маддәсенә туры китереп вазифасыннан баш тартса;

5) суд карары нигезендә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип табылса;

6) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;

7) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;

8) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины Районның җирле үзидарә органнарына сайлана ала, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртылып алынса;

11) сәламәтлеге буенча Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен башкара алмауы турында суд тәртибендә билгеләнсә;

12) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунга туры китереп тормышка ашырылган, Җирлекне үзгәртеп кору булган, шулай ук Җирлекне бетергән очракта;

13) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, җирлекнең сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә;

14) аның шәһәр округы белән кушылуы аркасында җирлекнең муниципаль берәмлек статусын югалтуы;

15) гражданнарның туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарларын тормышка ашыру өчен таләп ителгән муниципаль хокук актын бастырып чыгару срокларын бозу;

16) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канун һәм башка федераль кануннар билгеләгән чикләүләрне сакламаган очракта.

2. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт (вклад) ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм (яки) куллануны тыю турында” 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме белән чыгымы туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ Федераль кануны, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канун һәм башка федераль кануннар билгеләгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән һәм вазифаларын башкармаган очракта туктатыла.

3. Бу маддәнең 1нче өлешенең 1-11,14 һәм 15нче пунктларында күрсәтелгән дәлилләр буенча, Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Җирлек Башлыгын сайлау Җирлек Советының якындагы утырышында башкарыла.

4. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта яңа Җирлек Башлыгын сайлау мондый вәкаләтлек туктатылган көннән соң кимендә алты айдан соңга калмыйча сайлана.

Шул ук вакытта җирлек Советы вәкаләтләре вакыты чыгарга алты айдан ким вакыт калган булса, җирлек Советы составыннан җирлек башлыгын сайлау яңа сайланган җирлек Советының беренче утырышында тормышка ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Президентының (Татарстан Республикасы Премьер Министры) җирлек Башлыгын вазифадан азат итү турында хокук акты нигезендә, яки җирлек Советының җирлек Башлыгын отставкага җибәрү турында карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган җирлек Башлыгы әлеге хокук актын яки карарны суд тәртибендә шикаять бирә, суд карары законлы көченә кермичә җирлек Советы үзенең составыннан сайлана торган җирлек башлыгын сайлау турында карар кабул итергә хаклы түгел.

6. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яки аңа карата суд карары буенча кулга алып процессуаль көчләү чаралары кулланганда, яки вазифасыннан вакытлыча азат иткән вакытта аның вәкаләтләрен вакытлыча җирлек Башлыгы Урынбасары башкара.

**47нче маддә. Ышанычын югалту сәбәпле муниципаль вазифа башкаручы шәхесләрне эштән алу (вазифасыннан азат итү)**

1. Федераль кануннары, Татарстан Республикасы кануннары, муниципаль норматив хокук актларында каралган тәртиптә муниципаль вазифа башкаручы шәхесне ышанычын югалту сәбәпле эшеннән алу (вазифасыннан азат итү) түбәндәге очракларда була:

1) шәхеснең аның белән бәйле булган мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәүе;

2) үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны һәм хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны тапшырмаганда, яки дөрес булмаган, яки тулы булмаган мәгълуматлар тапшырганда;

3) федераль канун билгеләгән очраклардан кала түләүле нигездә коммерцияле оешманың идарә итү органы эшчәнлегендә катнашканда;

4) шәхес эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашырса;

5) Россия Федерациясе халыкара килешүе һәм Россия Федерациясе кануны белән башка нәрсә каралмаган булса, идарә итү органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, башка чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалар составына һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче аларның структур бүлекчәләре составына керсә.

2. Муниципаль вазифа башкаручы шәхес аңа буйсынган шәхеснең низах мәнфәгатьләрен китереп чыгарган яки чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынуы турында билгеле булса, ышанычын югалту сәбәпле эштән алынырга (вазифасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук аңа буйсынган шәхес низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрмәгән өчен ул башкарган вазифасыннан азат ителергә тиеш.

3. Муниципаль вазифа башкаручы шәхескә карата коррупцион хокук бозу башкарганы өчен ышанычын югалту сәбәпле эштән алу (вазифасыннан азат итү) кебек җәза куллану, анда шәхес тиешле вазифа башкарган җирле үзидарә органы тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль канунының 15нче маддәсендә каралган ышанычын югалту сәбәпле эштән алынган шәхесләр реестрына кертелә.

## Vнче бүлек. Җирлек Башкарма комитеты

**48нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты-Җирлек җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы**

1. Җирлек Башкарма комитеты- Җирлек җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы булып тора.

2. Җирлек Башкарма комитетының рәсми исеме – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты.

3. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек Советы белән хисаплашырга һәм контрольдә булырга тиеш.

4. Җирлек Башкарма комитетның мөһере һәм үзенең атамалары һәм билгеләнгән үрнәктә Җирлек гербы сурәте белән бланклары, шулай ук аңа тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт регистрациясе үткәрү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Россия Федерациясе гербы сурәте белән мөһере бар.

5. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыруга тотылган акча Россия Федерациясе чыгымнар классификациясенә туры китереп җирлек бюджетында аерым юл белән карала.

**49нчы маддә. Җирлек Башкарма комитеты структурасы**

1. Башкарма комитет структурасы Җирлек Советы тарафыннан Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе тәкъдим итүе буенча раслана.

2. Җирлек Башкарма комитеты структурасына Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасары, Башкарма комитетның башка дәүләт хезмәтендәге шәхесләре керә.

**50нче маддә. Башкарма комитет вәкаләтләре**

Җирлек Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм хисап өлкәсендә:

- Җирлек бюджеты проектын, Җирлек иҗтимагый-икътисад үсешенең комплекслы программаларын һәм план проектларын эшләүне тәэмин итә;
- Җирлек бюджеты, Җирлекнең иҗтимагый-икътисад үсешенең комплекслы программалары һәм план проектлары үтәлешен оештыра;
- Җирлекнең иҗтимагый-икътисад өлкәсенең торышын характерлаучы статистик күрсәткечләрне туплауны оештыра, һәм күрсәтелгән мәгълуматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт власте органнарына тапшыруны оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә, предприятие, учреждение һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- Җирлекнең муниципаль милкендә булган муниципаль мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, куллану, идарә итү һәм арендалау буенча мәсьәләләрне чишә;
- Җирлек Советы карары билгеләгән очракта, Җирлек Советы раслауына (килешүенә) милекне тартып алу турында, шул исәптән аны приватизацияләү турында тәкъдимнәрен әзерли һәм кертә ала ;
- муниципаль милектә булмаган предприятие һәм оешмалар белән Җирлекнең иҗтимагый-икътисад үсешендә хезмәттәшлек турында килешү төзи; Җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формаларын булдыруга булышлык итә;
- муниципаль заказларны формалаштыра, урнаштыра, муниципаль заказларның үтәлешен тормышка ашыра, бу эшләргә каралган Җирлекнең үзенең материал һәм финанс чараларын кулланып Җирлек кирәк-яраклары өчен эшләргә заказ бирүче була;
- “Коммерцияле булмаган оешмалар турында” 12нче гыйнвар, 1996нчы ел, №7-ФЗ Федераль канунының 31.1 һәм 31.3 маддәләре билгеләгән вәкаләтләре кысаларында социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтә;

3) территориаль планлаштыру, җирне һәм башка табигать ресурсларын куллану, әйләнә-тирә мохитны саклау өлкәсендә:

- Җирлек Советы раслауына Җирлекне территориаль планлаштыру документлары проектларын, һәм Россия Федерациясе Төзелеш кодексы белән туры китереп башка төзелеш документациясен әзерли һәм кертә, аларны тормышка ашыруны тәэмин итә;

- Җирлекнең муниципаль милкендә булган җирләрне рациональ куллану һәм саклауны планлаштыру һәм оештыруны тормышка ашыра;

- Җирлек территориясендә урнашкан җирләрне, канунда билгеләнгән тәртиптә, бирә, шул исәптән сатып алу юлы белән тартып ала;

- халыкка экологик хәл турында мәгълумат бирә, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең әйләнә-тирә мохитка зыян китерүче табигатьтән файдалану турында кануннарны боза торган гамәлләре турында тиешле органнарга хәбәр итә;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- муниципаль төзелеш фонды төзелешен һәм тотуны оештыра, аның хисабын алып бара, җирлек территориясендә торак төзелеше өчен уңайлыклар тудыруны тәэмин итә;

- җирлек торак пунктлары чикләрендә урын өчен әһәмиятле булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тормышка ашыра;

- муниципаль транспорт оешмаларын булдыру юлы белән, яки килешү буенча шәхси һәм башка транспорт оешмаларын транспорт хезмәте күрсәтергә җәлеп итү юлы белән халыкка транспорт уңайлыкларын булдыру өчен һәм муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра;

- халыкны элемтә хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;

5) авыл хуҗалыгы һәм эшмәкәрлек үсеше өлкәсендә:

- авыл хуҗалыгы производствосы үсешенә булышлык итә;

- кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә шартлар тудыра;

6) торак- коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- Россия Федерациясе кануны белән билгеләнгән вәкаләтләре кысаларында җирлек чикләрендә электр-, җылылык- һәм су белән тәэмин итүне оештыра;

- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәт күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- социаль найм килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ сыйфатындагы гражданнар исемлеген билгеләнгән тәртиптә алып бара;

- халыкның ялын оештыру өчен һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерүгә шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;

- җирлек территориясендә халыкның массакүләм ял итү өчен шартлар тудыра һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра, гомуми кулланышта булган су объектларына һәм аларның яр буена гражданнарның ирекле керүен тәэмин итә;

- күмү урыннарын карап тора, ритуаль хезмәтләрне оештыра;

- җирлекнең архив фондын формалаштыра;

7) төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), ташу, эшкәртү, юкка чыгару, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлеген оештыра;
- җирлек территориясен төзекләндерү буенча эшчәнлекне оештыра;
- адреслау объектларына адреслар бирә, адресларны юк итә, үзгәртә, урам-юл челтәрләре элементларына исемнәр бирә (федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларыннан кала, региональ автомобиль юллары яки муниципальара әһәмияткә ия булган юллардан кала), җирлек территорияләре чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәрен бирә, шул исемнәрне үзгәртә, юк итә, дәүләт адреслар реестрында мәгълуматны урнаштыра;

8) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш чаралардан саклау өлкәсендә:
- Җирлек территориясендә кануннарның, дәүләт власте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының актларын саклауны, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;
- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында дәүләт власте органнарының һәм дәүләт хезмәтендәге затларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җирле үзидарә хокукларын бозган актларына шикаять бирә;
- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм итә;
- халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын чыгу куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итә;
- үзенең вәкаләтләре кысаларында һәм билгеләнгән тәртиптә халыкка гадәттән тыш чараларның килеп чыгуы яки чыгарга мөмкин булуы турында вакытында кисәтү ясый һәм хәбәр итүне тәэмин итә;
- муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, җирлек депутатын чакырту буенча тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрүдә оештыру һәм материаль – техник тәэмин итүне тормышка ашыра, җирлек чикләрен үзгәртү буенча, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне тормышка ашыра;
- собраниеләр, митинглар, урам йөрешләре, демонстрация һәм пикетлауларны үткәрү, спорт, тамаша һәм башка массакүләм иҗтимагый чараларны оештыру белән бәйле булган законда каралган чараларны тормышка ашыра;
- җирлектә терроризмның асылын аңлату буенча һәм аның иҗтимагый куркыныч булуы турында мәгълумат- пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә, шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясен кабул итмәүне формалаштыру буенча, шул исәптән мәгълумат материалларын, басма продукцияне тарату юлы белән, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрүне оештыра;
- муниципаль милектә яки җирле үзидарә органнарының карамагында булган объектларны террорчылыкка каршы торуга таләпләрне үтәүне тәэмин итә;
- җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телен һәм мәдәниятен үстерүгә ярдәм итү, милләтләр арасында килешүне ныгытуга юнәлтелгән чараларны булдыру һәм тормышка ашыру, милли азчылыкны тәшкил иткән халыкларның хокукларын тормышка ашыру,

күчеп килгән халыкларның иҗтимагый һәм культуралы җайлашуын, милләтара (этникара) низахларны булдырмый калуны тәэмин итә;

9) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм уздыра;

10) Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән Җирлек җирле үзидрә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән Җирлек җирле үзидрә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үти;

- дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен бирелгән материаль һәм финанс чараларын тиешле кулллануны тәэмин итә һәм хисап алып бара;

- Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән туры китереп билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру турында хисап тапшыра;

- Җирлек Советы карары белән туры китереп тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәүне тормышка ашыру өчен Җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган материаль ресурсларны һәм финанс чараларын өстәмә кулллануны тәэмин итә;

11) башка вәкаләтләр:

- Җирлек Башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокук, мәгълумат, материаль-техник һәм башка тәэмин итүне тормышка ашыра;

- бу Уставның 5нче маддәсенең 1нче өлешенең 8-10, 17 һәм 20нче өлешләрендә каралган җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү максатыннан, гражданнарны ирекле нигездә җирлек өчен социаль әһәмиятле булган эшләргә (шул исәптән дежур тору) тарту турында карарлар кабул итә һәм аларның үтәлешен оештыра;

- канун белән, әлеге Устав белән, Җирлек Советы карарлары белән Җирлек Советы һәм Җирлекнең башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә караган вәкаләтләрдән тыш Җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча башка вәкаләтләрне башкара.

2.Башкарма комитет җирлекнең аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләргә карамаган мәсьәләләрне чишү буенча түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

- Җирлек музейларын булдыра;

- Җирлектә нотариус булмаган очракта канун белән каралган нотариаль гамәлләрне башкара;

- опека һәм тәрбиячелек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнаша;

- Җирлек территориясендәге җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле булган эшчәнлекне тормышка ашыруда булышлык итә;

- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара бәйләнешләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга булышлык итә;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләрне мобилизацион әзерләү буенча чараларны оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;

- муниципаль янгын сагы хезмәтен булдыра;

- туризмны үстерүгә шартлар тудыра;

- кеше хокукларын яклаучы иҗтимагый контрольне тормышка ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга булышлык итә;

- инвалидларның иҗтимагый оешмаларына ярдәм күрсәтә, шулай ук “Россия Федерациясендә инвалидларны иҗтимагый яклау турында” 24нче ноябрь, 1995нче ел, №181-ФЗ Федераль кануныna яраклаштырып бөтенроссия иҗтимагый инвалидлар оешмалары төзегән организацияләргә ярдәм итә;

- федераль кануннарда билгеләнгән шартлар һәм тәртип буенча оешмаларның хезмәт күрсәтүен бәйсез бәяләү тәртибен оештыру өчен шартлар тудыра;

- торак турында канун белән туры китереп гражданнарга муниципаль торак фонды торак йортларын социаль кулланудагы торак фонды торак йортларын найм килешүе буенча бирә;

- җирлек территориясендә яшәгән караусыз хайваннарны тотып алу һәм асрау буенча чараларны тормышка ашыра;

- “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” Федераль канунында каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны тормышка ашыра;

- инвалидларның, сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикле булган кешеләр өчен физик культура һәм спортны, җиңелләшкән спортны һәм җиңелләшкән физик культураны үстерүгә булышлык итә.

**51нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе.**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе укыту, фәнни һәм башка иҗади эш белән шөгыльләүдән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хаклы түгел; ләкин укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эш өчен түләү, Россия Федерациясе кануннарында һәм Россия Федерациясе халыкара килешүе белән башкача каралмаган очракта, чит дәүләт хисабына, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары акчасы хисабына була алмый. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе Россия Федерациясе кануннары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе белән башка нәрсә каралмаган очракта, Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче чит ил структур бүлекчәләре һәм дәүләтнеке булмаган һәм коммерцияле булмаган органнарына, идарә, попечительләр һәм күзәтүче органнар составына керергә хакы юк.

**52нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү тәртибе.**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.

2. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе өчен контракт шартлары Җирлек Советы тарафыннан раслана. Федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары тарафыннан Җирлекнең җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган очракта, Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнгән шартлар контрактка мәҗбүри рәвештә кертелә.

3. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына кандилатлар булырга тиеш:

- югары профессиональ белемле;

- муниципаль хезмәтнең вазифаи хезмәт төркеменә туры килгән яки аңа тигезләшкән дәүләт граждан хезмәтенең муниципаль вазифаларында ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы, яки белгечлек буенча дүрт елдан да ким булмаган стаж;

- Җирлек Советы карары билгеләгән күләмдә Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын башкару өчен кирәкле эшлеклелек сыйфатлары һәм осталыгы.

4. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләүгә конкурс әлеге Устав һәм Җирлек Советы карары билгеләгән тәртиптә үткәрелә.

5. Конкурс шартлары, аны үткәрү көне, вакыты, урыны, контракт проекты массакүләм мәгълумат чараларында конкурс үткәрелгәннән соң 20 көннән дә соңга калмыйча бастырылып чыгарыла.

6. Конкурсны уздыру өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны Җирлек Советы тарафыннан раслана.

7. Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы Җирлек Советы тарафыннан, ә калган яртысы – Югары Ослан Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

8. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына шәхес конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан билгеләнә.

9. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт Җирлек Башлыгы тарафыннан төзелә.

**53нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакыты.**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт шәхесне Җирлекнең Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасына билгеләү турында карар кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтлеге вакытына (яңа чакырылыш Җирлек Советы эш көне башланганчы) кадәр, ике елдан да ким булмаган вакытка төзелә.

2. Җирлек Советы вәкаләтләре вакыты чыккач, яңа Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләгәнче, Җирлекнең Башкарма комитет Җитәкчесе каралган тәртиптә үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.

**54нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре.**

Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе:

1) Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге белән берлек принципларында идарә итә һәм Җирлек Башкарма комитеты компетенциясенә кергән вәкаләтләрне үтәү өчен шәхси җаваплылык тота;

2) Җирлек Башкарма комитетын Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек башка җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль берәмлекләре, дәүләт власте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән бәйләнештә тәкъдим итә;

3) Җирлек Советы карауына җирлекнең бюджет проектын һәм аның үтәлеше турында хисапны тәкъдим итә;
4) Җирлекнең комплекслы иҗтимагый-икътисадый үсеш планы проектын һәм программасын Җирлек Советы карауына тәкъдим итә;
5) Җирлек Башкарма комитеты структурасы проектын Җирлек Советы раслауына кертә, җирлекнең муниципаль оешмаларының штат расписаниесен һәм төзелешен раслый;
6) Җирлек Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка эшчеләрне вазифаларына билгели һәм вазифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата мактау чараларын һәм дисциплина җаваплылыгын куллана;
7) үзенең вәкаләтләре кысаларында расланган бюджетка туры китереп Җирлек акчасы белән идарә итә;
8) Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән Җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыра һәм (яки) тормышка ашыруны тәэмин итә, аларның үтәлеше өчен шәхси җаваплылык алып бара; тиешле кануннар нигезендә һәм аларны үтәп тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле булган мәсьәләләр буенча хокук актлары чыгара;
9) Җирлек Башкарма комитеты компетенциясенә караган әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча хокук актлары чыгара, шулай ук Җирлек Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокук актлары чыгара;
10) Җирлек Советы контрольлегендә һәм отчётында, Җирлек Советына үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча һәм Башкарма комитет эшчәнлеге буенча, шул исәптән Җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне чишү буенча еллык хисап тапшыра;
11) Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими мәгълумат тапшырып тора, Җирлек Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга бер тапкырдан да ким булмаган гражданнарны шәхси кабул итүне оештыра, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карап тикшерә һәм алар буенча карарлар кабул итә;
12) дәүләт һәм башка органнарда Җирлек мәнфәгатьләрен яклау чараларын күрә, Җирлек Башкарма комитеты исеменнән судка гаризалар , ышанычнамәләр бирә;
13) Җирлек Советы раслауына Җирлек Башкарма комитеты органнары турында кагыйдәнамәләр проектларын тәкъдим итә;
14) муниципаль учреждениеләрнең җитәкчеләрен вазифаларына билгели һәм вазифаларыннан азат итә;
15) канунга, әлеге Уставка, Җирлек Советы карарларына һәм төзелгән контрактка туры китереп башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

**55нче маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:
1) үлгән очракта;
2) үз ризалагы белән отставкага китсә;

3) әлеге маддәнең 2нче пунктына туры китереп контракт өзелгән очракта;
4) гамәлдәге кануннарга туры китереп вазифасыннан баш тартса;
5) суд карары нигезендә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип табылса;
6) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;
7) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;
8) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;
9) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины Районның җирле үзидарә органнарына сайлана ала, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса;
10) хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә алынса;
11) федераль кануннарга туры китереп тормышка ашырылган, Җирлекне үзгәртеп кору булган, шулай ук Җирлекне бетергән очракта;
12) Җирлек чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә.
2. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча яки суд тәртибендә гариза нигезендә туктатыла:
1) Җирлек Советының һәм Җирлек Башлыгының контракт шартларының әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә кагылышлы өлешен бозу аркасында, шулай ук Уставның 49нчы маддәсендә билгеләнгән чикләүләрне сакламаган очракта;
2) контракт шартларының Федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән Районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга кагылышлы өлешен бозу аркасында, шулай ук Уставның 49нчы маддәсендә билгеләнгән чикләүләрне сакламаган очракта -Татарстан Президентының;
3) Җирле үзидарә органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары тарафыннан контракт шартларын бозу аркасында - Башкарма комитет Җитәкчесенең.
Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт суд тәртибендә Татарстан Республикасы Президенты гаризасы нигезендә “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме белән чыгымы туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ Федераль кануны, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт (вклад) ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм (яки) куллануны тыю турында” 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канун һәм башка федераль кануннар билгеләгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән һәм вазифаларын башкармаган очракта, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе кануны белән туры китереп тикшерү вакытында ачыкланган керемнәре турында, чыгымнары турында, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълуматларының дөрес һәм тулы булуы ачыклангач өзелергә мөмкин.

**VIнчы бүлек. Җирле үзидарәнең башка органнары. Җирле үзидарә органнарының үзара мөнәсәбәтләре**

**56нчы маддә. Җирлекнең Ревизия комиссиясе.**

1. Җирлекнең Ревизия комиссиясе җирле үзидарәнең даими финанс контроле коллегиаль органы.

2. Җирлекнең Ревизия комиссиясе рәис һәм ике әгъзадан тора.

Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыру, эшчәнлеге тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында” 7нче февраль, 2011нче ел, №6-ФЗ федераль кануны, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль кануны, Җирлек Советы раслаган җирлекнең Ревизия комиссиясе турында Кагыйдәнамәсе, башка муниципаль норматив хокук актлары белән билгеләнә.

Федераль кануннар билгеләгән очракларда һәм тәртиптә Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыруны һәм эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы кануннары белән тормышка ашырыла.

**57нче маддә. Җирлекнең Сайлау комиссиясе.**

1. Җирлекнең Сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, җирлек депутатын чакырту буенча тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрүне оештыра, җирлек чикләрен үзгәртү буенча, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне тормышка ашыра.

2. Җирлекнең Сайлау комиссиясе җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасына кермәгән муниципаль органы булып тора.

3. Җирлекнең Сайлау комиссиясе җирлек Советы тарафыннан федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануны һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы билгеләгән тәртиптә формалаша.

4. Җирлекнең Сайлау комиссиясе вәкаләтләре вакыты биш ел.

5. Җирлекнең Сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукы белән 6 әгъза исәбеннән формалаша.

6. Җирлекнең Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанслауны тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты классификациясе белән яраклаштырып җирлек бюджетында аерым юл белән карала.

7. Җирлекнең Сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлегенең тәртибе һәм гарантияләре федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары һәм әлеге Устав, җирлек Советы раслаган җирлекнең Сайлау комиссиясе турында Кагыйдәнамәсе белән җайга сала.

8. Җирлек Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк Сайлау комиссиясе карары буенча Җирлекнең Сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә тапшырыла ала.

**58нче маддә. Җирлек Советының, Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитетының һәм җирлек җирле үзидәрәсенең башка органнарының үзара мөнәсәбәтләренең нигезе**

1. Бу Кагыйдәнамәдә билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү белән туры китереп, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы һәм Җирлек Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль рәвештә башкара.
2. Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты кануннарда, бу Устав белән билгеләнгән формада Җирлекнең икътисади һәм иҗтимагый үсеше процессы белән нәтиҗәле идарә итү максатыннан һәм аның халкы ихтыяҗларыннан чыгып үзара бәйләнештә булырга тиеш.
3. Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты бер-берсенә кабул ителгән хокук актларын кул куелганнан соң җиде көн эчендә җибәрәләр.
4. Җирлек Советы Башлыгы Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе буларак, Җирлек Советына Җирлек Советы хокук актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү яки өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итергә хокуклы, шулай ук суд тәртибендә аларга шикаять белдерергә хокуклы.
5. Җирлек җирле үзидарәсенең башка органнарының үзара мөнәсәбәтләре тәртибе җирлек Советы тарафыннан билгеләнергә мөмкин.

**59нчы маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында бәхәсләрне чишү**

Җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен тормышка ашыру буенча бәхәсләр килешү яки суд тәртибендә чишелә.

## VIIнче бүлек. Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль органнары эшчәнлегенең гражданлык-хокук һәм финанс нигезләре

**60нчы маддә. Юридик шәхес хокукына ия булган Җирлекнең җирле үзидарә органнары**

1. Федераль кануннарга һәм әлеге Уставка туры китереп, юридик шәхес хокукы Җирлек Советына һәм Җирлек Башкарма комитетына бирелә.
2. Җирлек Советы карары буенча Җирлек Башкарма комитеты структурасы белән туры китереп, юридик шәхес хокукы җирлек Башкарма комитетының башка органнарына бирелә ала.

**61нче маддә. Юридик шәхес буларак Җирлекнең җирле үзидарә органнары**

1. Җирлек Башлыгы Җирлек исеменнән мөлкәт һәм башка хокук һәм бурычларны ала һәм тормышка ашыра ала, судта ышанычнамәдән башка чыгыш ясый ала.
2. Юридик шәхес хокукы бирелгән Җирлекнең җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен тормышка ашыру өчен барлыкка килгән муниципаль казна учреждениеләре булып торалар, һәм федераль кануннар билгеләгән тәртиптә юридик шәхес буларак дәүләт теркәүен узарга тиеш.

**62нче маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнарын финанслау**

Җирлекнең җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнарны финанслау бары тик Җирлек бюджетының үзенең кереме хисабына гына тормышка ашырыла.

**VIIIнче бүлек. Җирлек башлыгынына һәм Җирлекнең муниципаль вазифаларын башкаручы башка шәхесләренә бирелә торган иҗтимагый һәм башка гарантиеләр**

**63нче маддә. Җирлек башлыгынына һәм Җирлекнең муниципаль вазифаларын башкаручы башка шәхесләренә бирелә торган иҗтимагый һәм башка гарантиеләр**

Җирлек башлыгынына һәм Җирлекнең муниципаль вазифаларын башкаручы башка шәхесләренә бирелә торган иҗтимагый һәм башка гарантиеләр "Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы депутатының вәкаләтләрен тормышка ашыруда гарантияләре турында" 12нче февраль, 2009нчы ел, №15-ЗРТ Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп билгеләнә.

**64нче маддә. Җирлек Советы депутатының, башка дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең эшчәнлегенең иҗтимагый һәм башка гарантиеләре**

1. Азат ителмичә эшләүче Җирлек Советы депутатына Җирлек Советының һәм аның органнарының утырышларында катнашкан өчен, Җирлек Советының аерым йөкләмәләрен үтәгән вакытта гамәлдәге канун белән каралган акчалата түләү һәм башка түләүләр каралган.
2. Үзенең вәкаләтләрен азат ителеп башкаручы Җирлек Башлыгы урынбасарына, Җирлек Башлыгы вазифаларын башкарганда, бу Кагыйдәнамәдә каралганча, Җирлек Башлыгының айлык акчалата түләү күләменең 90% күләмендә акча түләү каралган.
3. Кануннарга, Җирлек Советы карарлары белән туры китереп Җирлекнең Ревизия комиссиясе әгъзаларына һәм Сайлау комиссиясе әгъзаларына бу органнарның эшендә катнашкан вакытта акчалата түләү каралган.

**65нче маддә. Җирлек Башлыгы, Җирлек Советы депутатларының иминлеге гарантияләре**

1. Җирлек Советы депутатлары, шул исәптән Җирлек Башлыгы хокукларын, аларны җинаять һәм административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлаганда, кулга алганда, тентү оештырганда, сорау алганда, аларга карата җинаять-процессуаль һәм административ – процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатка карата, аның эш бүлмәсен, багажын, шәхси һәм эш транспорт чараларын, язышу, кулланган элемтә чараларын, аңа кагылышлы документларны тикшерү буенча оператив- эзләү чаралары үткәргәндә, гарантияләр федераль кануннар белән билгеләнә.

2. Кануннарга яраклаштырып, Җирлек Советы депутаты тавыш биргәндә әйтелгән фикер, позиция өчен, аның статусына туры килгән башка гамәлләре, шул исәптән аның вәкаләтләре беткәнче, җинаять һәм административ җаваплылыкка тартыла алмый. Бу кагыйдәнамә Җирлек Советы депутаты тарафыннан халык алдында кимсетү, яла ягу һәм башка федераль кануннар белән җаваплылыкка тарту каралган тәртип бозулар булган очракларга карамый.

## IXнчы бүлек. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең җаваплылыгы

### 66нчы маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең җаваплылыгы

Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр федераль кануннарга туры китереп, Җирлек халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында җаваплы булалар.

### 67нче маддә. Җирлек Советы депутатларының Җирлек халкы алдында җаваплылыгы

1. Җирлек Советы депутатларының, шул исәптән Җирлек Башлыгының Җирлек халкы алдында җаваплылыгы әлеге депутатның аны сайлаган җирлек халкы ышанычын югалту нәтиҗәсендә башлана.
2. Җирлек халкының ышанычын югалткан Җирлек Советы депутаты, шул исәптән Җирлек Башлыгы, бу Устав белән каралган нигез буенча һәм тәртиптә чакыртып алына ала.

### 68нче маддә. Җирлекнең сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең дәүләт алдындагы җаваплылыклары

1. Федераль кануннарга туры китереп, Җирлек Советының, Җирлек Башлыгының дәүләт алдындагы җаваплылыгы Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституция кануннарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы кануннарын һәм бу Уставны бозган очракта чыгарылган суд карары нигезендә башлана, шулай ук Җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә тормышка ашырмаган очракта башлана.
2. Җирлек Советын тарату нигезе һәм тәртибе, җирлек Башлыгын вазифасыннан азат итү һәм отставкага җибәрү “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль кануны белән билгеләнә.

### 69нчы маддә. Җирлекнең сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы

Җирлекнең сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы федераль кануннар белән билгеләнгән тәртиптә башлана.

## Хнчы бүлек. Җирлекнең муниципаль хокук актлары

### 70нче маддә. Җирлекнең муниципаль хокук актлар системасы

1. Җирлекнең муниципаль хокук актлар системасына керәләр:
1) җирлек Уставы, җирле референдумда кабул ителгән хокук актлары;
2) Җирлек Советының норматив һәм башка хокук актлары;
3) Җирлек Башлыгының, Башкарма комитетның һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затлары һәм башка органнарның бу Устав белән каралган норматив һәм башка хокук актлары.

2. Җирлек Уставы һәм җирле Референдумда кабул ителгән карар килеш ясалган хокук актлары муниципаль хокук актлар системасында югары юридик көчкә ия булган актлар булып тора, туры көчкә ия һәм бөтен Җирлек территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокук актлары бу Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокук актларына каршы килергә тиеш түгел.

3. Җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары һәм органнары кабул иткән муниципаль хокук актлары бөтен Җирлек территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш.

4. Муниципаль хокук актлары, бу органнар яки вазифалар юкка чыгарылганда, муниципаль хокук актларын кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары тарафыннан юкка чыгарыла яки аларның гамәлдә булу вакыты туктатылып тора, яки бу органнарның һәм дәүләт хезмәтендәге затларның вәкаләтләре исемлеге җирле үзидарә органнары яки дәүләт хезмәтендәге затлары тарафыннан үзгәрсә, шулай ук суд тарафыннан юкка чыгарыла, ә федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләре җирле үзидарә органнары тарафыннан тормышка ашырылуын җайга салган өлешендә, Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары белән, яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары белән тормышка ашырылганда юкка чыгарыла.

5. Норматив характерда булмаган муниципаль хокук акты аны кабул иткән җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе тарафыннан эшмәкәрләрнең хокукларын саклау буенча вәкаләтлекләр турында канунга туры китереп бирелгән Россия Федерациясенең эшмәкәрләрнең хокукларын саклау буенча вәкаләтлекләр буенча канунына туры китереп, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилнең тиешле боерыгы алынган очракта, һичшиксез туктатыла. Алынган боерыкны үтәү турында муницпаль җирлек Башкарма комитеты яки җирлек җирле үзидарсенең дәүләт хезмәтендәге кешесе Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкиленә өч көн эчендә, ә Җирлек Советы – алар карар кабул иткән көннән соң өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итергә тиеш.

6. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыруны нигезсез кыенлаштырган кагыйдәнамәләрне ачыклау максатыннан эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокук актлары Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп муниципаль норматив хокук актлары билгеләгән тәртиптә җирле үзидарә органнары үткәргән экспертизаны узарга тиеш.

7. Муниципаль хокук актларын үтәмәгән өчен халык, оешма җитәкчеләре, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары дәүләт хезмәтендәге затлар, федераль кануннарга һәм административ хокук бозулар турындагы Татарстан Республикасы Кодексына яраклаштырып, җаваплы була.

**71нче маддә. Гражданнарның туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлары**

1. Аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне җирлек халкы тарафыннан чишү гражданнарның турыдан-туры җирле референдумда белдерелгән туры ихтыяр белдерү юлы белән тормышка ашырыла.

2. Җирлек халкы тарафыннан туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен өстәмә муниципаль хокук акты кабул итү (чыгару) кирәк икән, әлеге актны кабул итү (чыгару), аларның компетенцияләренә кергән Җирлекнең җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе, референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергәннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш.

3. Гражданнар тарафыннан туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен кирәкле булган муниципаль хокук актын бастырып чыгару сроклары бозылу, Җирлек Башлыгын чакыртып алу, Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга җирлек булып тора.

**72нче маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокук актларының төрләре**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр аларга йөкләтелгән вәкаләтләрне башкарганда түбәндәге муниципаль хокук актлары чыгаралар:

1) Җирлек Советы- Җирлек Советы карарлары;

2) Җирлек Башлыгы- Җирлек Башлыгы карарлары һәм әмерләре;

3) Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе –Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе карарлары һәм әмерләре.

2. Җирлекнең җирле үздарә дәүләт хезмәтендәге башка шәхесләр үзләренең вәкаләтләре кысаларында, аларның статусын билгеләүче бу Устав белән, башка муниципаль хокук актлары белән билгеләнгәнчә, әмерләр һәм боерыклар чыгаралар.

**73нче маддә. Муниципаль хокук актларын әзерләү**

1. Муниципаль хокук актлары проектлары Җирлек Башлыгы, Җирлек Советы депутатлары, Югары Ослан районы прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркеме, шулай ук аны алып бару мәсьәләләре буенча җирлекнең Ревизия комиссиясе тарафыннан кертелә ала.

2. Муниципаль хокук актлары проектларын кертү тәртибе, аңа беркетелә торган документларның исемлеге һәм формасы җирлекнең Совет Регламентына туры китереп һәм җирлек Башлыгы белән билгеләнә.

3. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокук актлары Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп муниципаль хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан җайга салу йогынтысын бәяләү үтәргә тиеш.

Муниципаль норматив хокук актларын җайга салу йогынтысын бәяләү "Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп муниципаль хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының сайлап куелган шәхесләре) тарафыннан үткәрелә.

4. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокук актларына экспертиза эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыруны нигезсез кыенлаштырган кагыйдәнамәләрне ачыклау максатыннан үткәрелә.

5. Муниципаль норматив хокук актларына экспертиза"Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп җирле үзидарәнең тиешле органнары раслаган планнар белән муниципаль хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының сайлап куелган шәхесләре) тарафыннан үткәрелә.

**74нче маддә. Җирлек Советының хокук актлары**

1. Җирлек Советы, аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча, Җирлек территориясендә үтәлергә тиешле кагыйдәләрне билгели торган карарлар кабул итә, Җирлек Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итә, шулай ук Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар һәм Федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары, Җирлек Уставы белән аның компетенциясенә караган башка сораулар буенча карарлар кабул итә.

2. Федераль кануннар белән башка нәрсә каралмаган булса, Җирлек Советы карарлары билгеләнгән Җирлек Советы депутатлары санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3. Җирле салым һәм җыюларны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгаруны, Җирлек бюджеты акчаларын тотуны тормышка ашыруны күздә тоткан Җирлек Советы карарлары Җирлек Советы тикшерүенә Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча яки аның бәяләмәсе булганда кертелә ала. Күрсәтелгән бәяләмә Җирлек Советына Җирлек Башкарма комитетына проект карары тапшырылгач утыз көн эчендә тапшырыла.

4. Җирлек Советы карарлары Җирлек Башлыгы тарафыннан аларны кабул иткәннән соң өч көн эчендә имзалана һәм бу Уставта билгеләнгән тәртиптә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

**75нче маддә. Җирлек Башлыгының хокук актлары**

Җирлек Башлыгы канунда, бу Уставта, Җирлек Советы карарларында билгеләгәнчә үзенең вәкаләтләре кысаларында, Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм боерыклар чыгара.

Җирлек Башлыгы бу Устав белән аның компетенциясенә караган үзенең вәкаләтләре кысаларында, башка мәсьәләләр буенча карарлар һәм боерыкларны "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында"Федераль кануны, башка федераль кануннар белән туры китереп чыгара.

**76нчы маддә. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе хокук актлары**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе канунда, бу Уставта, Җирлек Советы карарларында билгеләгәнчә, үзенең Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләре кысаларында, Җирлек җирле үзидарә органнарына федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән тапшырылган дәүләт вәкаләтлекләрен тормышка ашыру белән бәйле булган карарлар кабул итә, шулай ук Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча боерыклар чыгара.

**77нче маддә. Муниципаль хокук актларының бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм гамәлгә керү тәртибе**

1. Җирлек Советы карарлары, карар белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, Җирлек Башлыгы аларга кул куйгач, 10 көн узганнан соң үз көченә керә.

Җирлек Советының салым һәм җыюлар турындагы хокук актлары Россия Федерациясе Салым кодексына туры китереп үз көченә керә.

Җирлек Советының Җирлек Уставын кабул итү һәм бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары федераль кануннарда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең хокук актлары, бу актлар белән башка нәрсә каралмаса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Муниципаль берәмлекләр аларның оештыручысы булган организацияләрнең хокук статусын билгеләүче, кеше һәм гражданин хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокук актлары, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр аларны рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокук актының реквизитлары булырга тиеш: исеме, кул кую көне (Җирлек Советы кабул иткән хокук актларына–Җирлек Советы кабул иткән көн), регистрация номеры, хокук актына кул куйган дәүләт хезмәтендәге затның исеме.

5. Җирлек Советының, федераль кануннар белән аларны тарату чикләнгән муниципаль хокук актларыннан кала, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән Җирлек бюджеты турындагы карары, аның үтәлеше турында отчёты, җирле салым һәм җыемнарны билгеләү турында, Җирлек Советы тарафыннан кабул

ителгән башка норматив хокук актлары кул куелганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Рәсми рәвештә, җирле референдумны билгеләү турында, Җирлек чикләрен үзгәтү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре турында, Җирлек Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау турында, Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм аның урынбасарларын сайлау турында һәм канунга туры китереп башка норматив булмаган хокук актлары басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Норматив булмаган хокук актлары, кануннарга һәм бу Уставка туры китереп рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерелү) мөһим булмаганлыктан, аны чыгарган Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге затлар чыгарган карар буенча бастырылып (халыкка җиткерелә) чыгарыла ала.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткерелгәндә) муниципаль хокук актларының реквизитлары, “Идел яңалыклары” гәҗитенең чыккан көне, хокук акты текстын Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгарган көне, җирлекнең мәгълумат стендларында урнаштырылган көне күрсәтелә.

9. Муниципаль норматив һәм норматив булмаган хокук актларын рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) хокук акты текстын “Идел яңалыклары” район гәҗитендә, яки хокук акты текстын Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгару аша тормышка ашырыла.

Өстәмә рәвештә норматив хокук актлары Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырыла ала.

10. Муниципаль норматив һәм башка хокук актларын халыкка җиткерү гомуми мәгълуматны Җирлекнең мәгълумат стендларында урнаштыру юлы белән җиткерүдән гыйбәрәт. Күрсәтелгән мәгълумат стендларының саны, аларны урнаштыру урыннары җирлек Советы тарафыннанраслана һәм Җирлек халкының норматив һәм башка хокук актлары белән тоткарлыксыз танышуына мөмкинлек тәэмин итергә тиеш. Муниципаль норматив һәм башка хокук актлары күрсәтелгән мәгълумат стендларында аларны урнаштырган көннән алып 30 көн эчендә торырга тиеш.

11. Муниципаль хокук актлары, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокук акты карарлары итеп рәсмиләштерелгән җирле үзидарә органнарының хокук актлары Татарстан Республикасы кануны билгеләгән тәртиптә оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгы тарафыннан тормышка ашырылган Татарстан Республикасы норматив хокук актларының регистрына кертелергә тиеш.

## XIнче бүлек. Җирлекнең икътисади нигезе

### 78нче маддә. Җирлекнең икътисади нигезе

Җирлекнең икътисади нигезен Җирлекнең муниципаль милкендә булган мөлкәт, Җирлек бюджеты акчасы, шулай ук Җирлекнең мөлкәт хокуклары тәшкил итә.

**79нчы маддә. Җирлекнең муниципаль мөлкәте**

1. Җирлекнең милкендә була ала:

1) җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән билгеләнгән очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук ”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы канунының маддәсенең 4нче өлеше белән каралган тәртиптә аларга тапшырылган җирле үзидарә органнарының аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) Җирлек Советы Карары белән туры китереп Җирлекнең җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә вазифаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятие һәм учреждение эшчеләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына федераль кануннар белән кирәкле мәсьәләләрне чишү өчен аларны чишү хокукы бирелгән мөлкәт, һәм алар әһәмиятле булган мәсьәләләргә карамаган очракта;

5) федераль кануннарга туры китереп башка мөлкәт.

**80нче маддә. Җирлекнең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аны куллану һәм аның белән эш итү**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга һәм аларга туры китереп кабул ителгән җирлекнең җирле үзидарә органнары норматив – хокук актларына туры китереп, Җирлек исеменнән мөстәкыйль рәвештә муниципаль мөлкәткә ия булалар, аны кулланалар һәм аның белән эш итәләр.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне вакытлыча яки даими кулланырга физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт власте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирергә хокуклы, тартып алырга, федераль кануннарга туры китереп башка килешүләр ясарга хокуклы.

3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте башкарма властеның федераль органы вәкаләтлеге билгеләгән тәртиптә муниципаль мөлкәтнең реестрларын алып бара.

**81нче маддә. Муниципаль предприятие, учреждение һәм хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Җирлек муниципаль предприятие һәм учреждениеләр төзи, үзгәртеп кора һәм бетерә ала, шул исәптән әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкару өчен кирәк булган муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре төзүдә катнаша ала.

2. Оештырычы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашыручы җирле үзидарә органнары муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең эшчәнлеге максатын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, әлеге предприятие һәм учреждениеләрнең җитәкчеләрен вазифага

билгеле һәм вазифадан азат итә, бу Устав һәм муниципаль хокук актлары белән каралган тәртиптә аларның эшчәнлекләре турында отчётларны тыңлый.

3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Җирлек исеменнән муниципаль казна учреждениеләрнең бурычлары буенча субсидиар җавап бирәләр һәм федераль кануннар билгеләгән очракта һәм тәртиптә аларның үтәлүен тәэмин итәләр.

**82нче маддә. Җирлекнең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары**

1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль кануннарга туры китереп Җирлек Советы карарлары белән билгеләнә.

2. Муниципаль мөлкәтне куллану һәм хосусыйлаштырудан кергән керем Җирлек бюджетына керә.

**83нче маддә. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган муниципаль предприятие, учреждение һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре**

Җирлекнең җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган муниципаль предприятие, учреждение һәм оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, кануннар белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, килешү нигезендә төзелә.

**XIIнче бүлек. Җирлекнең финанс нигезе**

**84нче маддә. Җирлекнең бюджеты**

1. Җирлекнең үз бюджеты бар.

2. Җирлек бюджеты Җирлек Советы тарафыннан муниципаль хокук акты формасында эшләнә һәм раслана.

3. Җирлек бюджетында җирле үзидарә органнарының Җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруга юнәлтелгән чыгымнары аерым күздә тотыла, һәм Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан тормышка ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләре, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр хисабына тормышка ашырылган Җирлек бюджетының тиешле чыгымнары аерым күрсәтелә.

4. Җирлек җирле үзидарә органнары федераль кануннар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив- хокук актлары билгеләгән тәртиптә дәүләт властеның федераль органнарына һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт органнарына Җирлек бюджеты үтәлеше турында отчёт тапшыралар.

**85нче маддә. Җирлектә бюджет процессы**

1. Җирлек бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту Җирлек җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарыла. Җирлек бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль кануннар һәм алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы кануннарына туры китереп тормышка ашырыла.

2. Җирлек бюджеты проекты, Җирлек бюджетын раслау турында Җирлек Советы карары, аның үтәлеше турында еллык отчёт, Җирлек бюджетының үтәлеше барышы турында квартал отчёты һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль учреждение эшчеләренең саны турында, аларны тотуга киткән фактик чыгымнарын күрсәткән мәгълумат рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә)тиеш.

3. Җирлек Советының җирле салымнар турында муниципаль хокук актларына үзгәрешләр кертү турында норматив- хокук актлары, Җирлек Советының Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет чыгымнарын үзгәртүгә китерүче бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы алдагы финанс елында һәм планлы вакыт эчендә көченә керүче муниципаль хокук актлары, алдагы финанс елында һәм планлы вакыт эчендә көченә керүче муниципаль хокук актларын Җирлек Советына керткән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Җирлек бюджеты проекты өч елга төзелә һәм раслана (алдагы финанс елында һәм планлы чорга).

5. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Җирлек бюджеты проекты Җирлекнең иҗтимагый-икътисадый үсешен алдан әйтүгә таянып Җирлекнең чыгым йөкләмәләрен финанс тормышка ашыру нигезендә төзелә.

6. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Җирлек бюджеты проекты Җирлек Башкарма комитеты билгеләгән Россия Федерациясе Бюджет кодексы, аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставка туры китерелгән тәртиптә һәм вакытта төзелә.

7. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен билгели торган (бюджет сәясәтенә таләпләр) Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламалары кагыйдәнамәләрендә;
- иҗтимагый-икътисадый үсешен алдан әйтүдә;
- бюджет сәясәтенең һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрендә;
- муниципаль программаларда.

8. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карарда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль кануннар һәм алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Җирлек Советы муниципаль хокук актлары (бюджет турында карардан кала) билгеләгән тәртиптә, бюджетның керемнәренең төп күләме, чыгымнарының төп күләме, бюджет дефициты, шулай ук башка күрсәткечләр бюджетның төп тасвирламасы булырга тиеш.

9. Җирлек бюджеты турында карар белән расланалар:

- Җирлек бюджеты керемнәренең төп идарәчеләре исемлеге;

- Җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының төп идарәчеләре исемлеге;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорга бюджет чыгымнарын классификацияләүнең чыгымнары төрләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан маддәләр, төркемнәр (төркемнәр һәм төркемчәләр) арасында, муниципаль программалар һәм программадан тыш эшчәнлек юнәлешләре буенча ассигновать ителгән бюджет акчасын бүлү, шулай ук Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы кануны, Җирлек Советы Карарына туры китереп билгеләнгән очракларда бюджет чыгымнарын классификацияләүнең чыгымнары төрләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр арасында бүлү ;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорга бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорга чыгымнарының ведомство структурасында бюджет чыгымнарын классификацияләүнең чыгымнары төрләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан маддәләр, төркемнәр арасында ассигновать ителгән бюджет акчасын бүлү;

- ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән ассигновать ителгән бюджет акчасының гомуми күләме;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорда Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган һәм (яки) башка бюджетларга бирелгән бюджетара трансфертлар күләме;

- Җирлек бюджетының шартлы раслана торган (расланган) чыгымнарының гомуми күләме планлы чорның беренче елына Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең 2,5 проценттан ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган бюджетара трансфертлар хисабыннан каралган, тиешле максатларга каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмаганда), планлы чорның икенче елына Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең 5 проценттан ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган бюджетара трансфертлар хисабыннан каралган, тиешле максатларга каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмаганда);

- алдагы финанс елына һәм планлы чорына бюджет дефицитын финанслау чыганаклары;

- алдагы финанс елыннан соң килгән һәм планлы чор елыннан соң елның 1нче гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген күрсәтеп;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Җирлек Советы муниципаль хокук актларына туры китереп билгеләнгән Җирлек бюджетының башка күрсәткечләре.

10. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карар проекты планлы чорның расланган бюджетының планлы параметрларын үзгәртү юлы белән һәм планлы чорга бюджет проектының икенче елы параметрларын аларга өстәү юлы белән раслана.

Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карар проекты планлы чорның расланган бюджет күрсәткечләренә ачыклык кертә һәм планлы чорга төзелүче бюджетның икенче елы күрсәткечләрен раслый.

Җирлекнең расланган бюджетының планлы чорының параметрларына ачыклык кертү түбәндәгеләрне күздә тота:

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карар проектын карап чыгу кирәк булган күрсәткечләргә ачыклык кертүне раслау;

- Җирлек бюджеты чыгымнары ведомство структурасының расланган күрсәткечләрен арттыру яки киметү турында раслау, яки Җирлек бюджеты чыгымнарының өстәмә максатчан маддәләре һәм (яки) төркемнәре буенча аңа бюджеттан бүлеп бирелгән акча кертүне раслау.

11. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карар проекты белән беррәттән Җирлек Советына тәкъдим ителә:

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджет сәясәтенең һәм Җирлек салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- шушы финанс елының узган вакыты буенча Җирлекнең иҗтимагый – икътисадый үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм Җирлекнең иҗтимагый – икътисадый үсешенең шушы финанс елына көтелгән нәтиҗәләре;

- Җирлекнең иҗтимагый – икътисадый үсеше турында алдан әйтү;

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлекнең консолидир бюджетының төп тасвирламалары турында (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет җитешмәү ) алдан әйтү;

- Җирлек бюджеты проектына аңлатма язуы;

- бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методика проектлары) һәм исәп – хисаплары;

- алдагы финанс елы ахырына һәм планлы чорның һәм елының ахырына муниципаль бурычның өске чиге;

- шушы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

- Җирлек Советы, Җирлекнең Ревизия комиссиясе тәкъдим иткән Җирлекнең Башкарма комитеты белән күрсәтелгән бюджет сметаларына карата килешмәүчәнлекләр килеп чыккан очракта күрсәтелгән органнарның бюджет сметасы проектлары;

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты керемнәрен классификацияләү һәм Җирлек бюджетын финанслау чыганакларын маддәләр буенча санау;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставка туры китереп билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Муниципаль программалар һәм программадан тыш эшчәнлек юнәлешләре буенча ассигновать ителгән бюджет акчасын бүлү бюджеты турында карар расланган очракта бюджет турында карар проектына муниципаль программаларның паспортлары тәкъдим ителә.

Бюджет турында карарда ассигновать ителгән бюджет акчасын бүлү буенча кушымта булмаган очракта, бюджет акчасын бүлү буенча кушымта бюджет турында карар проектының аңлатма язуының тәкъдимнәр өлешенә кертелә.

12. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты проектын төзү Россия Федерациясе Бюджет кодексына, федераль кануннар, аларга туры китереп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тормышка ашырыла.

13. Җирлек Башкарма комитеты алдагы финанс елына һәм планлы чорга Җирлек бюджеты турында карар проектын шушы елның 15нче ноябреннән дә соңга калмыйча Җирлек Советы карап чыгуына кертә.

14. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга, Җирлек Советы муниципаль хокук акты белән билгеләнгән, Җирлек бюджеты турында карар проектын карап чыгу һәм аны раслау тәртибе, әлеге проектны карап чыгу һәм аны раслауны, алдагы финанс елының 1нче гыйнварына кадәр һәм планлы чоры башланганчы тәэмин итергә тиеш, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184нче маддәсе белән туры китереп күрсәтелгән карар белән күрсәткечләрне һәм характеристикаларны раслау күздә тотыла.

15. Җирлек бюджеты турында карар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм (яки) Җирлек бюджеты турында карар белән башка нәрсәләр каралмаган булса, 1нче гыйнвардан көченә керә һәм финанс елының 31нче декабренә кадәр гамәлдә була.

Җирлек бюджеты турында карар билгеләнгән вакытта рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә ) тиеш.

16. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Җирлек бюджетының баланслылыгын һәм федераль кануннар һәм Татарстан Республикасының кануннары билгеләгән бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча, бюджет процессын тормышка ашыру буенча, дефицит күләме, муниципаль бурычның күләме һәм структурасы, Җирлекнең бюджет йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә.

17. Җирлек бюджеты керемнәре Россия Федерациясе бюджет кануны белән, салымнар һәм җыемнар турында кануннар белән һәм башка мәҗбүри түләүләр турында кануннарга туры китереп формалаша.

18. Җирлек бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда тормышка ашырыла.

19. Җирлек бюджеты чыгымнарын тормышка ашыру, федераль кануннар һәм Татарстан Республикасының кануннары билгеләгән очраклардан кала, дәүләт властеның федераль органнары вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарын финанслауга рөхсәт ителми.

20. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп тормышка ашырыла.

**86нчы маддә. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы” 5нче май, 2013нче ел, №44-ФЗ Россия Федерациясе канунына туры китереп башкарыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу Җирлек бюджеты чаралары хисабына башкарыла.

**87нче маддә. Җирлек гражданнарының үзара салым чаралары**

1.Гражданнарның үзара салым чаралары аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне чишүне тормышка ашыру өчен гражданнарның бер тапкыр түләүе. Гражданнарның үзара салым

тәртибендә түләүләрнең күләме, алар өчен түләү күләме киметелгән, Җирлек (җирлек составына кергән торак пункты) гражданнарның гомуми санының 30 процентыннан артып китмәгән аерым гражданнар категорясеннән кала, Җирлекнең һәр гражданины өчен тигез күләмдә билгеләнә,

2. Әлеге маддәнең 1нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсенең 1нче өлешенең 4.1 пунты караган очракта, гражданнар җыенында хәл ителә.

**88нче маддә. Җирлекнең муниципаль бурыч алуы**

1. Җирлек муниципаль бурыч алуны тормышка ашырырга хокуклы, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Җирлек Уставы белән туры китереп муниципаль берәмлекләр исеменнән эчке базарда урнаштырылган Россия Федерациясе валютасында кыйммәтле кәгазьләр чыгару юлы белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка керүче муниципаль бурыч йөкләмәләре китереп чыгаручы кредитлар юлы белән тормышка ашырырга хокуклы.

2. Җирлек исеменнән муниципаль бурыч алуны тормышка ашыруга хокук Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән туры китереп Җирлекнең Башкарма комитетына бирелә.

**89нчы маддә. Җирлекнең җирле бюджеты үтәлеше**

1. Җирлекнең җирле бюджеты үтәлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп тормышка ашырыла.

2. Җирлек бюджеты кассаның гомуми булуы нигезендә һәм чыгымнарның исәптә булу нигезендә башкарыла.

3. Җирлек бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, Җирлек бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счётын ачу һәм алып бару Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

4. Җирлек бюджеты үтәлеше җыелма бюджет язмасы һәм җирлекнең касса планы нигезендә оештырыла.

**90нчы маддә. Бюджет отчёты. Җирлек бюджеты үтәлешенең еллык отчёты**

1. Җирлекнең бюджет отчёты еллык булып тора.

2. Җирлекнең бюджет отчёты бюджет чараларының тиешле төп администраторларының җыелма бюджет отчёты нигезендә Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан төзелә .

3. Җирлек бюджетының үтәлүе турында еллык отчёты Җирлек Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Җирлек Советына тәкъдим иткәнче, Җирлек бюджетының үтүлүе турында еллык отчёты төп администраторларының тышкы бюджет отчётын һәм Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчётына йомгак ясауны үз эченә алган эчке тикшерү узарга тиеш.

Җирлек бюджетының үтүлүе турында еллык отчётын эчке тикшерү әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп Җирлек Советы раслаган муниципаль хокук акты билгеләгән тәртиптә Җирлекнең Ревизия комиссиясе яки Җирлек Советы тарафыннан тормышка ашырыла.

5. Җирлекнең Башкарма комитеты аңа нәтиҗә әзерләү өчен Җирлек бюджетының үтүлүе турында отчётны шушы елның 1нче апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра. Җирлек бюджетының үтәлүе турында еллык отчётка нәтиҗә әзерләү төп администраторларының бюджет акчаларын еллык бюджетын тышкы тикшерүе мәгълуматлары нигезендә 1 айдан артмаган вакыт эчендә үткәрелә.

6. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчётына йомгак Җирлекнең Ревизия комиссиясе тарафыннан, бер үк вакытта Җирлекнең Башкарма комитетына юнәлтелеп, тәкъдим ителә.

7. Җирлекнең Башкарма комитеты ел саен шушы елның 1нче маеннан да соңга калмыйча Җирлек Советының карар проекты кушымтасы белән отчётлы финанс елы өчен Җирлек бюджетының үтүлүе турында, Җирлек бюджетының үтәлүе турында башка бюджет отчёты һәм Россия Федерациясе Бюджет кануннары белән каралган башка документларны Җирлек Советына тапшыра.

8. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын карап чыгу нәтиҗәләре буенча Җирлек Советы Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын раслау турында яки кире кагу турында карар кабул итә.

Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын Җирлек Советы кире каккан очракта, мәгълуматларның тулы булмаган яки дөрес булмаган фактларын бетерү өчен һәм 1 айдан да соңга калмыйча кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

9. Җирлек бюджетының үтәлеше турында карар белән Җирлек бюджетының гомуми керемнәре, чыгымнары һәм дефицит күләмен күрсәтеп, отчёт финанс елы өчен Җирлек бюджетының үтәлеше турында отчёты раслана.

Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык отчётын раслау турында Җирлек Советының карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджет керемнәренең классификация кодлары буенча Җирлекнең бюджет керемнәре ;
- бюджет керемнәренең керем төрләренең кодлары буенча Җирлекнең бюджет керемнәре, керемнәренең кече төрләре, бюджет керемнәренә караган дәүләт идарәсе операция секторларының классификациясе;
- Җирлекнең бюджет керемнәре идарә тармагы структуралары буенча Җирлекнең бюджет керемнәре;
- бюджет керемнәренең классификациясенең бүлекләре һәм кече бүлекчәләре буенча Җирлекнең бюджет керемнәре;
- бюджетларның дефицитын финанслау чыганакларын классификация кодлары буенча Җирлекнең бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары;
- төркемнәр, кече төркемнәр, маддәләр, бюджет дефицитын финанслау чыганаклары төрләренең кодлары буенча Җирлекнең бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары.

**91нче маддә. Муниципаль финанс контроле**

1. Муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет канунын һәм башка бюджет хокук бозуларны җайга салучы норматив хокук актларын үтәүне тәэмин итү максатыннан тормышка ашырыла.

Муниципаль финанс контроле эчке һәм тышкы, алдагы һәм аннан соңгы була ала.

2. Бюджет хокук бозулар өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Җирлекнең Ревизия комиссиясе контроль эшчәнлеге булып тора .

3. Бюджет хокук бозулар өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Җирлекнең Башкарма комитеты органы (дәүләт хезмәтендәге шәхесләр) булган муниципаль финанс органнары контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Алдагы муниципаль финанс контроле Җирлек бюджет системасының бюджеты үтәлгән вакытта бюджет бозылуларын кисәтү һәм булдырмый калу максатыннан тормышка ашырыла.

5. Аннан соңгы муниципаль финанс контроле, аларның үтәлеше, учёт һәм хисап законлы икәнен билгеләү максатыннан, Җирлек бюджет системасының бюджеты үтәлеше нәтиҗәләре буенча тормышка ашырыла.

**XIVнче бүлек. Җирлекнең Уставын кабул итү. Бу Уставка үзгәрешләр кертү**

**92нче маддә. Җирлекнең Уставы проектын әзерләү тәртибе, бу Уставка үзгәрешләр кертү**

1. Бу Уставка үзгәрешләр кертү турында Җирлек Уставы проекты, Җирлек Советы карары проекты Җирлек Советына Җирлек Башлыгы, Җирлек Советы депутатлары, җирлек прокуроры, иҗтимагый территориаль үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Җирлек Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен Җирлек Советы карары белән махсус комиссия төзелә ала. Әлеге комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары белгечләре, экспертлар чакырыла ала.

3. Җирлек Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проекты, аларны Җирлек Советы карап чыккан көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, кануннарга туры китереп Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә әлеге Устав проекты буенча тәкъдимнәрне, гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен исәпкә алып рәсми рәвештә бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, шулай ук гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен, җирлек Уставын Россия Федерациясе Конституциясе белән туры китереп әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта рәсми рәвештә бастырып чыгару кирәкми.

4. Җирлек Уставы проекты буенча Җирлек Советының бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карарын Җирлек Советында карап чыгу алдыннан бу Уставка туры китереп халык алдында тыңлаулар үткәрелә.

**93нче маддә. Җирлекнең Уставын кабул итү, бу Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Җирлек Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын Җирлек Советы Җирлек Советы Регламенты белән туры китереп икедән дә ким булмаган укылышта тормышка ашыра.

2. Җирлек Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын кабул иткәннән соң, беренче укылышта әлеге проект Җирлек Башлыгы тарафыннан Җирлек Советы депутатларына җибәрелә.

3. Җирлек Уставы, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән ике өлешендәге тавыш белән кабул ителә. Әгәр Җирлек Башлыгы Җирлек Советы рәисе вазифаларын башкарса, рәиснең тавышы Җирлек Уставын, Җирлек Уставы проектына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук актын кабул иткәндә Җирлек Советы депутаты тавышы булып исәпкә алына.

4. Җирлек Уставын яңа басмада үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук акты итеп язылышы рөхсәт итеми. Бу очракта Җирлекнкң яңа уставы кабул ителә, ә Җирлекнең башта гамәлдә булган Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук акты Җирлекнең яңа Уставы көченә кергән көннән көчен югалткан дип санала.

**94нче маддә. Җирлек Уставының, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карарның көченә керүе**

1. Җирлек Уставы, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар федераль кануннар белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү үткәрү өлкәсендә федераль органның вәкаләтле башкарма власте территориаль органында дәүләт теркәүен узарга тиеш.

2. Җирлек Уставы, бу Уставка үзгәрешләр кертү турында карар дәүләт теркәүен узаганнан соң, җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм рәсми рәвештә басылып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелергәннән соң) көченә керә.

Җирлек Башлыгы Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар дәүләт теркәүен узаганнан соң, муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү үткәрү өлкәсендә федераль органның вәкаләтле башкарма власте территориаль органында дәүләт теркәүен узганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Җирлек җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (вәкаләтләр, вәкаләтлекләр вакыты һәм җирле үзидарә дәүләт хезмәтендәге сайлап куелган шәхесләне сайлау тәртибеннән кала) үзгәртүче Җирлек Уставына керткән үзгәрешләр, Җирлек Уставына әлеге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокук актын кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң көченә керә.

4. Җирлекнең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокук акты белән кертелә һәм түбәндәгечә рәсмиләштерелә:

1) Җирлек рәисе һәм җирлек Башлыгы имзалаган Җирлек Советы карары, яки Җирлек Советы рәисе вазифаларын башкаручы җирлек рәисенең үзе тарафыннан;

2) Җирлек Советы кабул иткән  һәм җирлек рәисе имзалаган аерым норматив хокук акты белән. Бу очракта  әлеге норматив хокук актында җирлек Советының аны кабул итү турында реквизитлары куела. Җирлек Советының мондый карарына җирлек Уставына кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр  көченә керү турында күчеш нигезләмәләре һәм нормалары куелу рөхсәт ителми.